Хөсәен Җәгъфәр

# Кичерә һәм сөя белсеннәр

*Шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Җ78

Бу китапны чыгару өчен матди ярдәм күрсәткән «Петрокам» ААҖ генераль директоры Гаяз Җәмигъ улы Сәхаповка автор үзенең ихлас рәхмәтен белдерә.

**Җәгъфәр Х.Г.**

Кичерә һәм сөя белсеннәр: шигырьләр / Хөсәен Җәгъфәр; кереш сүз авт. Н.Габдуллина. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 255 б.

ISBN 978-5-298-01477-9

Түбән Кама шәһәрендә яшәүче шагыйрь Хөсәен Җәгъфәрнең бу китабында туган як, халык, милләт язмышы, әти-әни, сөйгән яр, мәхәббәт хакындагы лирик, публицистик шигырьләре урын алды.

ISBN 978-5-298-01477-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Җәгъфәр Х.Г., 2007

## КҮКТӘ ОЧМЫЙ ЕГЕТ, ҖИРДӘН АТЛЫЙ

Хөсәен Җәгъфәрнең әле дөньяга чыгып өлгермәгән шигырьләрен бер тын белән укып чыктым да кулыма каләм алдым. Ләкин каләм очы ак кәгазь битенә төртелеп калды: нәрсә язарга, ничек язарга? «Йөрәгең кушканны яз», — ди эчке дөньям. Талпынам, тик сүзләр дәрьясыннан үземә кирәклеләрен сайлап ала алмыйм. Әйе, шагыйрь генә эчке уй-кичерешләрен, энҗеләрне бер җепкә тезгән кебек, матур итеп ача ала-дыр. Ә мин шул шигырьләргә мөкиббән киткән гади укучы гына шул.

Җиргә гашыйк булып туганмындыр,
Шуңа күрә йөреп туялмыйм,
Бу дөньяның сихри матурлыгын
Һич кенә дә күреп туялмыйм.

*(«Их син, дөнья!»)*

Әйе, күктә очмый, җирдән атлый шагыйрь. Бу аңлашыла да: Хөсәен Җәгъфәр туган ягы, авылының сөекле улы булудан тыш, гомерен авыл хуҗалыгына багышлаган кеше бит.

Атлап киләм авыл урамыннан —
Нинди тынлык, нинди рәхәтлек!
Аклык белән тулы бу җирләрем
Тәннәремә бирә сихәтлек, —

*(«Авыр уйлар күбрәк керәдер»)*
дип яза да.

Фанилыктан киткән чагында
Шул туфракта булсын гүребез, —

(«Туган туфрак»)
дип өстәп куя.
Х.Җәгъфәр күктән очмый, җирдән атлый. Туган авылы, Керәч-тау, Ишкәй күле, ялгыз нарат, гомумән, табигать, туган туфрак турында язган шигырьләрен укыганда, үзең дә аңа ияреп Иштирәк авылы урамында йөргәндәй, үз күзләрең белән Керәч-таудан ургылып кар суы агуын күргәндәй, инде юкка чыккан ялгыз нарат күләгәсендә ял иткәндәй буласың.
Ләкин шагыйрьнең күңеле китек, чөнки аның туган җиренә «химия кул суза»:

Бөтенесе юкка чыкты,
Җимерелде, тапталды.
Химкомбинат гигантының
Аяк астында калды.

*(«Чаң сугарга вакыт»)*

Әйе, Хөсәен Җәгъфәрнең борчылу капчыгы шактый зур: алдашу-йолдашу, наркомания, авылларның юкка чыгуы, халкының эчүгә сабышуы, гади халыкның авыр тормышы, ятим балаларның артуы турында язган шигырьләрен укыганда, күзләр дымлана.

Әйтерсең лә бу авылның
Кыйбласы югалган.
Эчкечелек алып узган,
Хәмер белән юылган.

Аналарга мәдхия җырламаучы шагыйрь юктыр бу дөньяда. Хөсәен Җәгъфәрнең дә андый шигырьләре шактый, һәм һәркайсында Ана образының бер ягы ачыла: игезәкләрен ак биләүгә биләүче ана, түгәрәк өстәл артына җыелган балаларын кара чуенда пешкән ашы белән сыйлаучы ана, кытыршыланып беткән куллары белән оныкларын иркәләүче әби, басу юлында, карашын олы юлга төбәп басып торучы ана. Шул ук вакытта автор:

Туган якның юмарт табигате,
Якын итеп, сине үз күргән.
Бөтен тирә-якны сокландырып,
Бер сылуы итеп үстергән, —

дип, укучыларга әнисен табигать тудырган сылу итеп күрсәтергә тели. Ә этисе Гомәр ага «Авылның иң оста гармунчысы, Менә дигән балта остасы» икән («Әткәйгә»).
Шагыйрьнең күп кенә шигырьләре якыннарына, дусларына багышлана. Ә менә мәхәббәт лирикасының төп герое — тормыш юлдашы Лилия.

Сине юатырдай сүзләр эзләп,
Гизәр идем ерак юлларны.
Шул сүзләрдән генә тукыр идем
Сиңа атап язган җырларны.

(«Сине юатырдай сүзләр эзлим»)

Шул ук вакытта еракта, туган ягы Тукай районы, Иштирәк авылының Керәч-тавында, тын гына аккан Тонгыч елгасы, чишмә буйларында, гармун моңына күмелгән айлы җәйге кичләрендә, буранлы кышларында адашып калган шаян яшьлеге аның шигырьләренә килеп керә.
«Шигырьләрем кебек шаулап ага», — дип яза Х.Җәгъфәр. Әйе, аның шигырьләре, ярларына сыеша алмый ташып аккан елганы хәтерләтә. Теле үткен, шул ук вакытта йомшак та. Сүзләре авылча гади кебек тоелса да, күңелгә шулкадәр якын, аһәңле яңгырый. Фикере кыска, ләкин тирән, тулы һәм заманга авазлаш.
Юк, нигә дип әле мин китап турында тәфсилләп язам? Иманым камил, аның шигырьләрен укучы да мин кичергән хисләр дәрьясына кереп чумар һәм, китапның соңгы битен япмый торып, аннан чыга алмас.

*Нурисә Габдуллина*

## ТУГАЙЛАРДАН КҮЗЕМ АЛАЛМЫЙМ

Чыгып килгән кояш нурларында
Иркәләнә басу-кырларым.
Бу җирләргә әллә соң кояш та
Мулрак сибә микән нурларын?

Күз карашы җитмәс киң басулар
Җәелеп китә ерак-еракка.
Җылысы да, яңгыр сулары да
Шифа булган юмарт туфракка.

Талгын җилдә салмак дулкынланган
Тугайлардан күзем алалмыйм.
Гомерлеккә иген кырларына
Гашыйк малай булып калам мин.

## АЕРМАСЫН ТУГАН АВЫЛДАН!

Күз күреме җитмәс ераклыкка
Сузылып киткән авылым кырлары.
Гомерлеккә отып алды күңелем
Шул кырларда шыткан җырларны.

Аяз күкле туган авылым белән
Горурланам һәрбер урында.
Челтер чишмәләре тыңлап туймас
Көй чыгара аның турында.

Бер уйласаң, безнең бу якларда
Сокланырлык җирләр азмы соң?
Тик шулай да туган авылымнан
Аермасын мине язмышым.

## ЗӘҢГӘР КҮЛЕМ

Ишкәемнең салмак дулкыннары
Сабый чактан якын күңелгә.
Искә алсам аны, бар уйларым
Хатирәләр белән күмелә.

Яшьлегемнең монда үтүенә,
Мәхәббәтем чәчәк атканга
Ишкәй күлем шаһит,
Ул көч бирде,
Зәңгәр дулкыннарын какканда.

Зәңгәр Ишкәй күле, туган авыл —
Икесе дә миңа бик якын.
Шулар өчен җырым, күңел җылым —
Йөрәгемдә сүнмәс ут-ялкын.

## ЧУЛМАН БУЙЛАРЫНДА УЙЛАНУ

Басып торам Чулман ярларында,
Канат җилпи татлы уйларым.
Хыялымда күпме иңләсәм дә,
Бу җирләрне күреп туймамын.

Дулкыннарның шавын тыңлаганда,
Бөтен кайгыларым онтыла.
Дулкыннардай шашкын, ярсу күңелем,
Белмим, шулай кая омтыла!

Йөрәгемә тынгы бирмәс хисләр
Юлдаш, ахры, миңа бишектән.
Шуңа микән әллә үземне мин
Уттан яралгандай хис итәм.

## КҮҢЕЛЛӘРГӘ ЯКТЫ НУР ТУЛСЫН

Алсуланып кояш чыгып килә,
Өр-яңа көн туа дөньяга.
Азга гына ялга талган авылым
Тагын йокысыннан уяна.

Чиратлашып аваз сала әнә
Әтәчләре, үрдәк-казлары.
Шушы микән әллә табигатьнең
Җырлар белән җирне назлавы.

Сихри тынлык кинәт артка чигә,
Бар тирә-як күмелә шау-шуга.
Әйтерсең лә язгы таң атуга,
Тормыш үзе күчә басуга.

Игенче дус, бүген тәүге тапкыр
Туам микән җиргә әллә мин?!
Ихлас теләгемнең иң изгесен
Телим сиңа шушы мәлдә мин.

Кырларыңда синең һәрчак шулай
Тук башаклар шаулап утырсын.
Бөеклеген тоеп хезмәтеңнең
Күңелләргә якты нур тулсын.

## ГОРУРЛАНЫП ЯШИМ СИНЕҢ БЕЛӘН

Сиңа кайткан саен, Иштирәгем,
Матурлыгың күреп туялмыйм.
Күпме теләкләрем рас килә дә,
Чынга аша күпме хыялым!

Күз алдымда минем яңарасың,
Бөтен җиреңкиткән яктырып.
Яңа калкып чыккан таш йортларың
Тора гүя үзенә чакырып.

Могҗизалар шулай туа мәллә,
Юкка чыга иске өйләрең.
Элеккедән җылырак тоела төсле
Каршы яктан искән җилләрең.

Кайда гына булмыйм, синең белән
Горурланам, туган авылым.
Сыкранмыйча, җиңеп яшик шулай
Бу тормышның җилен, давылын.

## КИТӘ АЛМАМ КЕБЕК

Зәңгәрлегән җуймас күк йөзендә
Ак болытлар йөзә тын гына.
Һәр тарафта иген басулары
Күмелгәннәр тургай моңына.

Һичбер байлыкка да алмаштырмам
Җәйнең шушы гүзәл мәлләрен.
Иснәп-сулап туймас һавасыннан
Дәва ала җаным-тәннәрем.

Тын да алмый тыңлыйм чәчәк күмгән
Аланнарда кошлар сайравын.
Күрүләре бәхет түгелмени
Дусларымның чалгы кайравын?!

Онытмыйлар алар халкыбызның
Уен-көлке, гадәт-йоласын.
Яннарында күңел ачып китсәң,
Мәңге яшәр кебек буласың.

И туган як, истән чыкмас өчен,
Гомерлеккә керден уема.
Синнән аерылып, чит җирләргә
Китә алмам кебек тоела.

## КИЛДЕМ СИҢА

Җиңәрлек көч бармы икән җирдә
Күңелдәге хисләр ташкынын?
Хыялымда, кечкенәдән бирле,
Сине күрер өчен ашкындым.

Инде менә күпме еллар үткәч,
Килдем сиңа, сусап белемгә.
Казан, Казан, тормыш маягымны
Кабыздың син гомерем күгендә.

Шул маякка карап атлаганда,
Йөргән юлларымда абынмам.
Җирне яраттырдың... Һәр адымымда
Туган туфрагыма табынам.

Гомер юлым соңгы көнемәчә
Үкенмәслек булып узылсын,
Иккән кырларымда бәрәкәтле
Буразналар булып сузылсын.

## ТУГАН АВЫЛЫМ

Иксез-чиксез булып тирә-якта
Җәйрәп ята болын-кырларың.
Бер күрүдә үзенә гашыйк итә
Эш сөючән сылу кызларың.

Горурлана алам, туган авылым,
Синең белән барган җиремдә.
Тормыш матур, яшәү рәхәт синдә
Хезмәтчел һәм гадел кешегә.

Шуңамы соң әллә үкенмимен
Туганыма һич тә мин монда.
Халкым белән бергә бәхет таңын
Каршыларга уйлыйм авылда.

## ИХ СИН, ДӨНЬЯ!..

Җиргә гашыйк булып туганмындыр,
Шуңа күрә йөреп туялмыйм.
Бу дөньяның сихри матурлыгын
Һич кенә дә күреп туялмыйм.

Кая барсам, кайда йөрсәм дә мин,
Каршы ала барыр юлымнан.
Их син, дөнья! Нинди матур соң син!
Миннән сәлам — газиз улыңнан!

Һәр көн саен шулай каршылыймын,
Күкне күзләп, туар таңнарны.
И Ходаем, берүк бу бәхеттән
Мәхрүм итмә бездәй җаннарны.

## ДУСЛАР ГАФУ ИТСЕН

Авылым, сиңа булган мәхәббәтем,
Ни әйтсәң дә, барыбер көчлерәк.
Тагын менә сиңа юл тотамын,
Иштирәгем минем, Иштирәк.

Күзләремне һич тә ала алмыйм
Ерактагы басу түреннән.
Һаман үзенә тарта, туфрагына
Магнитлармы әллә күмелгән?

Кеше, белмим, ничек кичерәдер

Аерылуны туган ягыннан?
Чәчәкләрен генә түгел, аның
Әременә хәтле сагынам.

Үзен яраттырган әллә бер-бер
Тылсымнары бармы соң аның?..
Җаннарыма бетмәс шифа алам,
Чишмәсенең эчсәм суларын.

Болыннарга чыксам, кузгалаклар
Исе килеп бәрелә борынга.
Дуслар гафу итәр, бер үк сүзләр
Кабатланса әгәр җырымда.

Үз гомеремдә азмы сукмак-юллар
Сузылып калган минем артымда...
Шул сукмаклар буйлап, әй, бер генә
Малай чактан урап кайтырга!

## КИЛМӘСМЕНИ ЙӨЗЕП КИТӘСЕМ?!

Күңел минем моңсу иртәләрдә
Су буйларын төшеп күзәтә.
Талга кунган сайрар сандугачның
Канатларын җилләр тибрәтә.

Нинди матур суның агышлары,
Су кызыдай килә йөзәсем.
Җаным шулай сусап тилмергәндә,
Килмәсмени йөзеп китәсем?!

## ЯРАТАМ МИН

Яратам мин ярсу инешемнең
Талларына карап җырларга.
Язын ярларына сыймый аккан
Суларының шавын тыңларга.

Җырым, син дә шулай ярга каккан
Дулкыннарның серен белсәңче.
Наз-моңнарга гашыйк дусларымның
Күңеленә үтеп керсәңче.

## КЫШЛАРЫ БИТ ЯЗЛАР БУЛАЛМЫЙ

Камышлар да инде саргайдылар,
Күлләр калды никтер боегып.
Җир өсләрен каурыйларга күмеп,
Аккошлар да китте кагынып.

Китә алар, кышларга дип китә,
Кышлары бит язлар булалмый.
Уйный буран, җелегеңә үтеп,

Ыжгырмыйча җилләр калалмый.

Көйсез, салкын бу кышларны күреп,
Алынмасын берүк котыгыз.
Калмагыз сез! Һәрчак җәйләр булган
Чит җирләргә юллар тотыгыз.

Очар юлыгызда афәтләргә
Юлыкмыйча юллар узылсын.
Арган чакта төшеп ял итәргә
Күл-елгалар алда гел булсын.

Китәләр шул, китеп барулары,
Кай илләргә барыр юллары?
Илләреннән киткән кошкайларның
Ни хакында икән уйлары?

Ап-ак каурыйлар сибеп җиргә,
Исә көзнең ачы җилләре.
Бөтенләйгә түгел, вакытлыча
Булсын анда яшәр көннәре.

Исән-имин кайтуларын теләп,
Туган җирдә атсын бу таңнар.
Аккошларны шулай озатып калган
Камышларның хәлен кем аңлар?

## ГОМЕРЕМНЕҢ ТАГЫН БЕР КӨНЕ

Таңнан хәбәр биреп кояш калка,
Болытларга сибеп нурларын.
Нинди рәхәт күреп-тоеп тору
Иркәләвен иген кырларын!

Синең таңнарыңны каршыларга
Ничек яратам мин, туган җир!
Төн карасын куып, син бит һаман
Гел яктылык белән тулган җир.

Кичке эңгер төшкән минутларда
Кояш гүя үзе моңлана.
Акрын гына зәңгәр урманнарның
Кочагына кереп югала.

Әнә шулай үтеп китә минем
Гомеремнең тагын бер көне.
Мизгелләрдән торган шул көн миңа
Күпме яшәү көче бөркеде!

## ТУГАН ТУФРАК

Туган җирләремә аяк баскач,
Иелеп, бер уч туфрак аламын.

Кулъяулыкка төреп, иплəп кенə
Түш кесəмə аны саламын.

Язмышына буйсынып, күпме затлар
Чит җирлəрдə гомер кичерə.
Үзəклəре өзелеп сагынганда,
Туган ягын исенə төшерə.

Кемне генə дəшеп кайтармый ул,
Кемнəр генə аңа табынмый,
Кемнең генə күңелендə аңа
Сөю уты дөрлəп кабынмый.

Шушы туфрактан бит яралдык без,
Беребез дə күктəн төшмəдек.
Маңгай тиребез белəн ашлап аны,
Гомер буе янып эшлəдек.

Туган-үскəн җирдə яланаяк
Йөргəн чакларымны сагынам.
Гомерем чигенəчə язмыш мине
Аермасын туган ягымнан.

Бар нəрсəдəн кадерлерəк безгə
Туфраккае, хəтта тузаны.
Һəрчак шулай күкрəк түрендəге
Кесəбездə йөртик без аны.

Исəн чагыбызда һəрберебез
Шул туфракка басып йөрибез.
Фанилыктан киткəн чагында да
Шул туфракта булсын гүребез.

## КЫРЛАРЫҢДА ТУГАН МОҢНАРЫҢ

Их, игенче, нинди бəхетле син!
Каршылыйсың туар таңнарны.
Бер тыңласаң иде онытылып
Кырларыңда туган моңнарны.

Тыңлыйсыңмы, тыңла бер утырып,
Иген шавын, кошлар сайравын.
«Сарыкбаш»ның саргылт болынында
Егетлəрнең чалгы кайравын.

Гомер белəн бергə шул туфракта
Үтеп киткəн еллар агышы.
Ə əнкəйлəр урак урган җирдə
Ишетелə мотор тавышы.

Шул авазлар бергə кушыла да
Моңлы бер җыр булып агыла.
Чыгыш ясый кебек зур ансамбль
Əйтерсең лə синең алдыңда!

## ДУЛКЫНЛАНСЫН КЫРЛАР!

Дулкынлана басу, офыккача
Агылганда башак ташкыны.
Игенченең күңелендә һәрчак
Тынгысызлык, кырга ашкыну.

Шул ипекәй өчен борчылулар,
Ут йотулар күпме буладыр?
Үткән гомер, тамган тирләре дә
Шул туфракка сеңеп каладыр.

Тыныч кына бу кырларны берүк
Чүп үләне күмеп китмәсен!
Тук игеннәр үссен дулкынланып,
Йөрәкләрдә ялкын сүнмәсен!

## ТАГЫН ЯЗЛАР КИЛДЕ

Әле кайчан гына ак кар белән
Томаланган иде җир өсте.
Ак бүреген салды басу-кырлар,
Ямьле язга кыш та биреште.

Кар астыннан гөрләвекләр ага,
Умырзая башын калкыта,
Илаһи ямь биреп бар җиһанга,
Яз кояшы җирне балкыта.

Җылы җилләр белән шаярышып,
Күктә кошлар канат кагына.
Сөенмәслекмени: нинди гүзәл
Яз килде бит туган ягыма.

## ТУГАН ЯКНЫҢ ЯКТЫ ЯЗЫНА

Әле кайчан гына килгән кышның
Узганын да сизми калганбыз.
Җирне йокысыннан уятучы
Яңа язны каршы алабыз.

Ап-ак тунын сала басу-кырлар,
Челтер гөрләвекләр гөр килә.
Бакчаларда борын төртеп чыккан
Чәчәкләрдән хуш ис бөркелә.

Үз юлларын таба кар сулары,
Ярларыннан чыга ташулар.
Тынгылыгын җуйган ул ташулар
Безнең йөрәкләрдәй ярсулар.

Исән-имин кайтып җиттек, диеп,
Сайрар кошлар канат кагына.
Бу дөньяда ниләр җитәр икән
Туган якның якты язына!

## КЕРӘЧ-ТАУ

Керәч-тау ягына карасаң,
Нурыннан күзләрең чагыла.
Үзең дә сизмисең, шул яктан
Җаныңа якты моң агыла.

Бер чыксаң, күңелең гомергә
Тартылыр рәхәтлек сәйранга.
Дөньяны йодрыктай йөрәккә
Сыйдырсам, калмагыз хәйранга.

Бабамнар ерактан килгәннәр
Атаклы Керәч-тау куенына.
Һәм шунда төпләнеп калганнар,
Яшәргә гасырлар буена.

Шуңамы, мондагы кешеләр
Беркатлы, риясыз, көчлеләр.
Кирәксә, әҗәлнең үзеннән
Аралап алачак төслеләр.

Шул җирдән беркая китминен,
Китәргә ниятләп килмәдем.
Яраттым мин аның кояшын,
Үзәккә үткәзгән җилләрен.

Тормышым, язмышым шушында,
Шушында — Керәч-тау иңендә.
Бу якның җырына-моңына
Моңнарым кушылсын минем дә.

Ут өстәү кирәкми, йөрәгем
Болай да бигрәк тиз кабына.
Тик аның җылысы, яктысы
Өстәлсен кешеләр җанына.

Өстәлсен җиһанны яктырып,
Юлдашы булсын ул аларның.
Керәч-тау, Керәч-тау, Керәч-тау,
Таңнарың, әй, синең таңнарың!

## ЯРАТАМ МИН СИНЕ, АЛТЫН КӨЗ

Яратам мин сине, алтын көз,
Синдәге һәр яңа чалымны.
Сап-сары яфраклар сибелеп,
Җир өстен бизәгән чагыңны.

Күзәтәм тәбәнәк болытлар
Күк йөзен колачлап алганын.
Хәтфәдәй уҗымнар өстенә

Сибәләп яңгырлар яуганын.

Яратам мин сине, алтын көз,
Син нинди төсләргә кермисең!
Җәй белән хушлашкан күңелемдә
Әкияти җыр булып йөрисең.

Синдәге камышлы күлләргә
Сокланмый икән соң кем генә!
Күзләрен дым сарган талларның
Төшенү озакмы теленә...

Яратам мин сине, алтын көз,
Дәвалы, шифалы сулышың.
Син шулай һәрвакыт үзеңдә
Саклыйсың туган җир җылысын.

Шуңа да ап-ачык тоясың
Тормышның шатлыгын, бар моңын,
Болытлар артыннан чыгарга
Җыенган кояшның барлыгын.

## ОНЫТМАГАН ТУГАН АВЫЛЫМ

Тагын кайтам менә авылыма,
Җир-суларым дәшеп кайтара.
Кай җирләргә китеп яшәсәң дә,
Җитми икән туган якларга.

Юл кырында үскән ак каеннар
Янәшәмнән атлап баралар.
Башакларын җилдә тибрәлдереп,
Арышларым каршы алалар.

Онытырсың диеп ялгышканмын,
Таныйсың бит, авылым, таныйсың.
Ятсынмыйсың, миңа элеккечә
Үз малаең итеп карыйсың.

Талгын гына аккан инешеңнең
Әсир булып тыңлыйм тавышын.
Суларының көче җитәр микән
Басар өчен йөрәк сагышын.

Киртләч тауларыңа арка терәп,
Утырасым килә киерелеп.
Таныш сукмаклардан кайтып килəм,
Татлы хыялларга бирелеп.

## БАБАМНАР КИЛГӘН ЕРАКТАН

Каф таулары кайтавазы булып
Күккә үрмәләгән Керәч-тау.
Ерактан ук аваз сала сыман:

— Мин бит әле һаман исән-сау.

Ял итәргә тукталыгыз миңа,
Сәфәр чыкканнарга юл озын.
Тәнегезгә сихәт-дәва булыр,
Һәрчак әзер сыем — кымызым.

Куенымнан чыккан чишмә суын
Кемнәр генә авыз итмәгән!
Ул тудырган моңлы көй-җырларны
Кемнәр генә тыңлап үтмәгән!

Гасыр ярым элек бабаларым
Килгән монда Кыргыз ягыннан.
Алар кебек мин дә шушы җирдә
Гомер итәм сабый чагымнан.

Әй, бу тормыш адәм балаларын
Кая гына илтеп ташламый.
Шул язмышка дучар булучылар
Кайда гына тормыш башламый.

Гаепсезгә кагылу-сугылуларга
Кемнең көче җитәр түзәргә...
Туган илен ташлап, мескен бәндә
Чыгып киткән бәхет эзләргә.

Юл тоткан ул шулай күз күрмәгән,
Колак ишетмәгән якларга.
Җиңел булган дисеңмени аңа,
Тау-далалар кичкән чакларда.

Берсе дә бит урын-җирен түшәп,
Кочак җәеп каршы алмаган.
Тик Керәч-тау, күрмәмешкә салышып,
Бер як читтә басып калмаган.

Мосафирны һич тә ят итмәгән,
Якын иткән, аны үз күргән.
Шушы җирдә яшәп калу өчен,
Иңнәреннән сыйпап, көч биргән.

Җилләре дә ашыкмаган аны
Башка тарафларга әйдәргә.
Насыйп булган тормышларын шулай
Шушы яклар белән бәйләргә.

Ата-бабаларым, чөкердәшеп,
Гомер кичергәннәр шушында.
Алар токымына бер-бер артлы
Оныклары килеп кушыла.

Кушылалар җырлы гомерләрен
Ялгар өчен алар гомеренә.
Туар көнгә булган ышанычның
Сүнмәс уты яна күңелемдә.

## ЕРАК БАБАМНАРНЫҢ МОҢ-ЗАРЫ

Кай тарафтан, кайсы чордан башлап
Исә икән Болгар җилләре?
Кемне генә үзенә тартмый икән
Изге нигез — Болгар җирләре!

Карап торам Идел ярларыннан,
Күзләремне текәп еракка.
Тарих төпкеленнән күтәрелеп,
Болгар моңы чыңлый колакта.

Идел, Идел! Тау-ташларга бәрелеп,
Нигә шулай ярсып агасың?
Күп гасырлар буе җыелып килгән
Ачуыңны кемнән аласың?

Изге туфрагыңа учак ягып,
Болгар төне белән сөйләштем.
Көн яктысын үзләренә җыйган
Йолдызларга карап эндәштем:

— Биеклектән сез дә күрәсезме
Кан саркылган изге ташларны?
Мәңгелеккә ятып калган монда
Бабамнарның газиз башлары.

Баскынчылар ыргылганнар барысын
Ватып-җимереп, таптап узарга.
Чыңгыз улы, кемнәр кушты сиңа
Бу җирләргә кулың сузарга?

Аксак Тимер, ахмак Тимер, әйтче,
Ул җирләрдә сиңа ни калган?
Беркем ала алмас мәшһүр шәһәр
Утлы божра белән камалган.

Бу җирләрдә ничә мәртәбәләр
Нинди яулар булып китмәгән?!
Болгар илен сытып узар өчен
Кемнәр генә һөҗүм итмәгән?!

Хәрабәләр тулы ул җирләрдә
Басып калган кече манара.
Басып калган ерак гасырларның
Бер ядкаре итеп карарга.

Шушы җирнең кайнар туфрагына
Азмы күз яшьләре түгелгән.
Туган халкым азмы газап чиккән,
Исән калыр өчен үлемнән.

Аның каны, күз яшьләре белән
Сугарылган туфрак-тузаны.

Кайтавазлар булып яңгырый һаман
Ерак бабамнарның моң-зары.

## МАЛАЙ ЧАГЫМ ҖЫРЫН ИШЕТӘМ

Җанга якын туган ягымнан
Күпме гомер аерым торылган!
Канатланып менә авылыма
Кайтып киләм басу юлыннан.

Күреп, мине каршы алырга
Әнкәм чыккан капка төбенә.
Насыйп икән йомшак чирәмдә
Яланаяк чабып йөрергә.

Искә төшә яшел аланда
Тайлар саклап яткан чакларым.
Ләкин элеккечә кешнәшеп
Көтмиләрдер инде атларым.

Җыр сузасы иде тагын бер
Үзебез генә белгән көйләргә.
Соңардык шул инде, ул еллар
Калды бары сагынып сөйләргә.

Ә шулай да һаман үземне
Сабый бала кебек хис итәм.
Аяк баскач таныш нигезгә,
Малай чагым җырын ишетәм.

## КОДРӘТЕҢНӘН КИЛСӘ

Кая икән, авылым, хәзер синең
Тал-тирәкле инеш буйларың?
Күлләреңә кайткан аккош кебек,
Шул чакларга кайта уйларым.

Боргаланып аккан суларыңның
Челтерәвен гүя ишетәм.
Үземне мин хәтфә үләннәргә
Басып йөргән кебек хис итәм.

Чишмә челтерәвен тыңлый-тыңлый,
Чирәмеңдә ауныйм бүген дә.
Күптән онытылган хис-тойгылар
Җырлар булып күчкән күңелгә.

Юк шул инде, юк шул, табигатьнең
Кабатланмас хәзер ул чагы.
Әллә кайчан пыскып сүнгән инде
Балачакның нәни учагы.

Без сокланган сихри гүзәллекләр
Күптән калган «диңгез» төбендә.

Алар инде әкият булып кына
Сөйләнәләр халык телендә.

Бер шаһиты булып ул көннәрнең
Тик Керәч-тау баса каршыма.
Кодрәтеңнән килсә, әй, Керәч-тау,
Кире кайтар безгә барсын да.

## КИЧЕРӘ АЛСАҢ ИДЕ, НИГЕЗ-ЙОРТ!

Синдә үтте безнең сыенышып,
Чыр-чу килгән шаулы балачак.
Һичбер кайчан, мәңге онытылмас
Хатирәләр булып калачак.

Ерак еллар томанында калган
Иске йортым керә төшемә.
Ятак-сәкеләрдә аунап үскән
Балачакны искә төшерә.

Барчабызның җанын уйнаклатып
Атыладыр мичтә очкыннар.
Таңнан торып безгә аваз салган
Әтәченә кадәр якыннар.

Җәйләреңдә һәр яфрагың синең,
Һәрбер чәчкәң илтә пакьлеккә.
Кышларыңда нәфис кар бөртегең
Җирне күмә иде аклыкка.

Ата-баба нигезен калдырып,
Юллар тоттык шау-шу калага.
Ә бит җаннар ничек өзгәләнде,
Кайтасылар килеп салага.

Тәрәзәдән күзләп, газиз ана
Күпме күз яшьләрен сөрткәндер.
Йөргән юллар урау булса да,
Кайтырлар, дип, безне көткәндер.

Кайда булмыйк, гомер юлларыбыз
Авыл белән тыгыз бәйләнгән.
Таң алдыннан җанга килеп кунган
Сагышлы җыр булып көйләнгән.

Син, нигез-йорт, безне җил-яңгырдан,
Салкын-бураннардан саклadың.
Кышның шомлы озын төннәрендә
Сукыр лампалардан ут алдың.

Искерсәң дә, шактый картайсаң да,
Үзең җылы, чыдам булгансың.
Кыйшайгансың, ләкин һаман да син
Горур булып торып калгансың.

## БАШКА ҖИРДӘ ТҮГЕЛ

Беркайчан да аерылмаслык булып
Бәйләнгәндер аңа уйларым.
Еллар узган саен, туган җирнең
Якынлыгын ныграк тоямын.

Онтылмаслык якты хатирәләр
Еракларда озата киләләр.
Һәр мизгеле изге — бу тормышны
Яратасың икән син әгәр.

Башка җирдә түгел, тик шушында
Бөтен гүзәллеге җиһанның.
Тормышны мин шулай һичберкайчан
Сөеп туймасыма ышандым.

Еракларда үзләренә дәшкән
Таулары гына да ни тора!
Күз тигезә күрмәгез сез берүк
Әткәм-әнкәм, бабам йортына.

## ӨЙ КАРШЫНДА ҮСКӘН ЧЫРШЫЛАР

Өй каршында үскән пар чыршылар
Булды һәрчак минем янымда.
Киткән чакта озатып калды алар,
Каршы алды кайткан чагымда.

Хәтеремдә саклыйм мин аларның
Баш очында шаулап торганын.
Яшьлегемә ялкын өстәп янган
Хисләремә сердәш булганын.

Охшашлыкларына кем сокланмас,
Игезәкләр диеп белерсең.
Сиздермичә килгән афәтләрдән
Ышыклыйлар иде бер-берсен.

Бер-берләрен назлап, талгын гына
Тирбәләләр иде таңнарда.
Күз тигәнме әллә көтмәгәндә,
Нәрсә булган бүген аларга?

Көчле давылдан соң берсе әнә
Авып төшкән койма буена.
Авыр ярасыннан һаман әле
Каны саркый сыман тоела.

Зәһәр җилгә ләгънәт укый-укый,
Җир-әнкәбез үкси тын гына.
Сабырлыклар бирсен, түзәр өчен
Чыршыларның кайгы-моңына.

Таянычын, сыңар ишен җуйган
Ялгыз чыршы тора бер читтә.
Җылы сүзләр табып, боек күңелен
Юатасы иде ничек тә.

Беркайчан да, димен, ялгызыңны
Калдырмабыз җилдә, яңгырда.
Туган җирдә ниләр кичерсәк тә,
Язмышыбыз бер үк тамырда.

## Ә НИГӘ СОҢ ӘЛЕ...

Чайкалдырып ап-ак каеннарны,
Җилләр дулый биек үрләрдә.
Ә нигә соң әле яшь имәннәр
Басып калган аста, түбәндә?

Ник кочмыйлар алар каеннарны,
Сизәләр бит давыл килгәнне.
Эх, күрәсем килде шунда минем
Тауга менеп барган имәнне.

## ГОМЕРКӘЙЛӘР ӘРӘМ УЗМАСЫН

Хәсрәтләрем таулар кебек чакта
Йөрәккәем ярсып тибенә:
Шул тибенгән йөрәгемне, кочып,
Салып куям учның төбенә.

Кайгыларым бераз басылсын дип,
Килә кайчак үксеп елыйсым,
Чишмә булып аккан күз яшемнең
Тамчысын да җиргә коймыйсым!

Нинди генә хәлләр кичерсәк тә,
Яратырга кирәк дөньясын.
Тормыш авыр диеп зарлансак та,
Гомеркәйләр әрәм узмасын!

## АВЫЛДАН АЕРЫЛГАЧ

Саубуллашып чыгып киткән чакта
Зурдан иде дә соң өметем!
Казан, имеш, киң кочагын җәеп
Каршы ала авыл егетен.

Туйдым хәзер шәһәр шау-шуыннан,
Күңелем тарта туган якларга.
Йөрәк әллә шулай урталайга
Бүленә микән андый чакларда.

Һич аңлата алмыйм, әллә ничек

Моңсу үтә монда көннәрем:
Төшләремдә күрәм авылымның
Һәр чокырын, һәрбер түмгәген.

Күз алдыма килә офыккача
Сузылып киткән яшел болыннар
Ат сакларга баргач, малай чакта
Учак ягып яткан урыннар.

Күтәрелеп карыйм зәңгәр күккә,
Ак болытлар йөзә тын гына.
Болытлар да уралгандыр сыман
Безнең якның сихри моңына.

Ул моңнарның серле кочагына
Минем хисләрем дә сыенган.
Әй, туктагыз әле, бергәләшеп
Урап килик авыл буеннан.

## МИНЕ, ЗИНҺАР, КҮКТӘН ЭЗЛӘМӘГЕЗ

Үрелеп буем җитмәс йолдызларга
Ымсынсам да кайчак җырымда.
Бигрәк артык хыялый бу диеп
Уйламагыз минем турыда.

Мине, зинһар, күктән эзләмәгез,
Мин бит шушы җирнең баласы.
Килә минем гомерем чигенәчә
Җир кешесе булып каласы.

Мин бары тик шушы җирдә генә
Яратамын таңнар атканын.
Нурга күмеп ерак офыкларны,
Алсуланып шәфәкъ батканын.

Җәйге иртәләрдә килә минем
Тауларыма карап торасым.
Әсирләнеп тургай моңнарына,
Үземнең дә тургай буласым.

Күктә түгел, җирдә ишетермен
Башак шавын, кошлар сайравын.
Яңгыратып болын киңлекләрен,
Дусларымның чалгы кайравын.

Күктән мине, зинһар, эзләмәгез,
Үтсен җирдә гомер юлларым.
Җир өстенә көн дә бәхет теләп,
Сузылсыннар минем кулларым.

Зинһар, мине күктән эзләмәгез,
Җирдә тормыш кыен булса да,
Чиксез галәм түгел, изге миңа
Туган нигез, туган бусага.

Таш кыялар кебек басып калыйк
Шушы җирдә гомер итәргә.
Ир-егетләр тормыш авырлыгын
Иңнәренә салып күтәрә.

Сыкранмыйча узган юлларында
Тирән уелып кала эзләре.
Йолдызларны көнләштереп яшик,
Җиргә гашыйк булсын үзләре.

## ТУГАН ЯКНЫҢ СИХРИ КӨЧЕ

Кычкыралар: «Кая машинаң, — дип, —
Утыр әйдә безнең арбага».
Юк, утырмыйм әле, авылдашлар,
Җәяү генә кайтыйм авылга.

Туган якның искән җилләренең
Тәнгә таралыдыр шифасы.
Үзе дәва, кирәкмидер табиб
Биргән даруларның файдасы.

Ул гына да түгел, табигатьнең
Матурлыгын ныклап күзлисең.
Тау өстеннән чыгар кояшыңны
Күз алмасы кебек эзлисең.

Күрче, нинди матур бит бу җиһан!
Дөнья алсу нурга күмелгән.
Болын-кырларымнан килгән хуш ис
Офыкларга кадәр сибелгән.

Тыныч кына кырлар йоклый иде,
Йоклый иде яшел болыннар.
Тау астыннан чабып атлар узды,
Артларыннан калмый колыннар.

Коча-коча арыш сабакларын,
Кереп китте алар бәйләнеп.
Тоякларын күккә чөя-чөя,
Колыннары ятты әйләнеп.

Шунда кинәт әчкелт арыш исе
Килеп кермәсенме борынга!
Рәхмәтлемен башак чыңын тыңлап,
Үз җиремдә басып торганга.

Ә ул җирдә ничек килмәсен соң
Башны күккә чөеп атасы,
Бер туйганчы камыл исен иснәп,
Зәңгәр күккә карап ятасы.

Сабыйларча, онытып бар дөньяны,
Эх, иркенләп тагын йөрергә!

Тик ярамый, картлар көтә булыр,
Кирәк тизрәк кайтып керергә.

Ә мин, юньсез, тынгысызлап иртүк
Нигә йөримендер картларны.
Шулчак бераз тынычландым кебек,
Тәрәзәдән күреп утларны.

Юкка гына борчылганмын икән,
Күптән инде алар торганнар.
Мин керәсе ишек-капкаларны
Әллә кайчан ачып куйганнар.

## ЯЛГЫЗ НАРАТ ХАТИРӘСЕ

Ул юк инде...
Аны минем кадәр
Сагына алмас хәзер беркем дә.
Яшел ботакларын аска иеп
Утыра иде язмыш иркендә.

Ә без, шук малайлар, чыр-чу килеп
Уйный идек аның төбендә:
Җыйнаулашып, иркен кочагына
Сыена идек көннең көнендә.

Чит итмәде безне һичбер вакыт,
Ышыклады хәтәр җилләрдән.
Әйтерсең лә күңелләребезгә
Шул чакта ук тамыр җибәргән.

Үткәннәрнең хатирәсе итеп
Искә төшерәм аны һаман да.
Үз янына дәшеп алыр кебек,
Таныш юлдан узып барганда.

Ылыслары белән иңнәремнән
Сыйпап калыр кебек әле дә.
Ләкин үзе исән чакта аның
Керә белмәгәнбез хәленә.

Соңлаганбыз кыен чакларында
Яклаучысы булып калырга:
Баш очына инде килеп баскан
Газраилдән йолып алырга.

Шуңа да бит кинәт мәхрүм калдык
Аның салмак, сихри моңыннан.
...Дөнья куйды нарат табигатькә
Хөсет җанлы бәндә кулыннан.

## ИГЕНЧЕ СИН...

Күрче инде, күрче, як-ягыңны
Ак каеннар чолгап алганнар.
Каеннарның зифа буй-сынына

Киң тугайлар хәйран калганнар.

Дулкын кагып, шулар кочагында
Баш калкыта куе арышлар.
Сабый чагыңнан ук исләре дә,
Җырлары да сиңа танышлар.

Уй-карашың һаман басуларда,
Көннәр кызу, коры торса да.
Үз-үзеңне онытып куанасың,
Яңгыр җиле исеп куйса да.

Игенче син, җирнең үз баласы,
Тынгысызлык синең юлдашың.
Алны-ялны белми янып яшә,
Гомерең берүк эзсез узмасын.

## КАЛА КЕШЕЛӘРЕ СЫЙЛАНСЫН

Күзәтмичә ничек тормак кирәк
Авылымның кичке гамьнәрен.
Күрше-күлән утыра гәпләшеп,
Бер-беренә сөйләп хәлләрен.

Көтү кайта, сыерлары мөгри,
Артларыннан туза тузаннар.
Иң өстенә чыбыркысын салган
Көтүчене көтә урамнар.

Тын һавада мөгрәү тавышлары
Күчә сыман Керәч-тауларга.
Әйтерсең лә шулай сәлам бирә
Сөтбикәләр кичен аларга.

Шул малкайлар хакына булса да,
Тормышыбыз бераз җайлансын.
Яңа сауган җылы сөтләреннән
Кала кешеләре сыйлансын.

## ӘЙ УЛ ЕЛЛАР, ҮТКӘН ГОМЕРЛӘР

Әй ул еллар, үткән гомерләр
Кире кайтса икән яңадан.
Тоеп яшәр идем үземне мин
Кабат туган кебек анадан.

Моңа кадәр узган юлыбызда
Ни җитмәгән бездәй ирләргә:
Әллә бәхет, әллә рәхәт эзләп
Йөрелгән ич чит-ят җирләрдә.

Уйларында, хыял канатында
Кемнәр генә күккә ашмаган!
Офыкларга карап атлаганда,

Кая гына аяк басмаган!

Әй ул еллар, үткән гомерләр,
Күңелләрнең чая, көр чагы.
Ялкынланып-дөрләп яна һаман
Балачакның нәни учагы.

Яшәүдән ни мәгънә, шул учагың
Әүвәлгедәй җылытып янмаса...
Бәхет биргән кешең читтә түгел,
Үз яныңда яши ләбаса.

Борынгылар юкка гынамыни
Салкын боз дигәннәр читләрне.
Әй ул бозны эретер өчен синең
Йөрәк кайнарлыгың җитәрме?!

Әй ул еллар, үткән гомерләр...
Сыный, ахры, безне язмышлар.
Кыска гына гомер эчендә дә
Күпме булды безнең ялгышлар.

Шул чактагы рухи яралардан
Җаннарыбыз сызлый әле дә:
Кайгыларга дучар булганнарның
Керә белмәгәнбез хәленә.

Ник заяга китте икән шулай
Дәвага дип кылган эшебез.
Егылганны тартып торгызырга
Җитмәс идемени көчебез.

Әй ул еллар, үткән гомерләр
Безне бүген ныграк уйлатсын.
Һәрбер гамәлебез кешеләрдә
Туар көнгә өмет уятсын.

Түгелмәсен җирдә күз яшьләре,
Сабыйларның күңеле шат булсын.
Күзебезне текәп кояш көткән
Күкләребез аяз саф булсын.

Талмасыннар каләм белән бергә
Чалгы-көрәк тоткан кулларым.
Газиз җирләремнән һичбер кайчан
Аермасын барыр юлларым.

## ИПЕКӘЙНЕ ҺӘРЧАК КАДЕРЛИК

Аркалардан кагып җилләр исә,
Адымымны барам тизләтеп.
Игеннәрдән шулчак бушап калган
Басуларны йөрим күзәтеп.

Үзем атлыйм, үзем уйланамын,

Күпме бөртек җиргә сибелгән.
Әйтерсең лә, чәчкән җиргә охшап,
Яшеллеккә кырлар күмелгән.

Чама белми кайчак игеннәрне
Теземнәргә салып ташлыйбыз.
Яңгыр ява, бөртекләре чери,
Җирне шулай итеп ашлыйбыз.

Йотарлардай булып кырларыңны
Ялмап алган утлы өермә.
Нинди мәхшәр диеп уйланырсың,
Ничек кирәк, шулай өерә.

Салам яна, аның белән бергә —
Сугылмыйча калган башаклар.
Аңлый алмыйм, ник соң бу кадәрле
Кадерсезгә калды ашлыклар?

Бар иде бит шул саламнар өчен
Ерак илләр-җирләр гизгән чак.
Ул вакытлар әллә онытылды,
Саламнардан бигрәк бизгән чак.

Гектарыннан җиде-сигез центнер
Уңышка да кайчак сөендек.
Унбишенә орден-медаль алып,
Герой бирмәгәнгә көендек.

Төшкә кермәс, күңел ышанмаслык
Чикләрне дә узып барабыз.
Илле, алтмыш центнер уңыш алып,
Тик нигәдер мантый алмыйбыз.

Нинди уңышларга ирешсәк тә,
Ипекәйне һәрчак кадерлик.
Кырларында мул уңышлар үскән
Игенчегә тел-теш тидермик.

## ВАКЫТЛЫЧА БУЛА КҮРМӘСЕН

Комбайннар гөрли... Басу-кырлар
Мотор тавышына күмелә.
Хезмәт шау-шуының кайтавазы
Җырлар булып үрли күңелгә.

Көр авазлар иңли тугайларны,
Барып сарыла таулар иңенә.
Бар яктылык җиргә игенченең
Күңел нуры булып сибелә.

Йөрәкләрдә янган шатлык хисе
Сүрелүне белми дөрләсен.
Җир-ананың шатлык-куанычы
Вакытлыча була күрмәсен.

## ИСКӘ АЛЫП МАЛАЙ ЧАКЛАРНЫ

Нигә шулай бик тиз узып киткән
Малай чаклар, гамьсез вакытлар.
Ачлы-туклы гомер кичерсәк тә,
Күңел тулы иде шатлыклар.

Аякларга киез итек киеп,
Боз өстендә шара куабыз.
Узышырга теләп бер-беребездән,
Керәч-таудан чана шуабыз.

Нинди генә уен уйнамадык,
Ныгытмалар салдык карлардан.
Әйтерсең лә җилдән җитезләр без,
Әй элдерттек биек таулардан.

Күпме генә уен уйнасак та,
Берсе дә бит истән китмәгән.
Депутатлар булып уйнарга тик
Беребезнең дә башы җитмәгән.

Хәзер инде авыл балалары
Текә таудан чана шумыйлар.
«Видик» карап, сагыз чәйни-чәйни,
Рэкетирлар булып уйныйлар.

Малай-шалай түгел, агайлар да
Туеп җитми икән уеннан.
Ил башлыгы, премьер, депутатлар
Уены бездә әйбәт куелган.

Уйный-уйный илне тараттылар,
Коры сүздән ботка пешереп.
Бөтен дөнья хәзер хәйран кала,
«Бөек илне» искә төшереп.

## ЧӨГЕНДЕРЛӘР ГӨРЛӘП УТЫРА

Көтү кугач, авыл хатыннары,
Китмәннәрен тотып кулларга,
Тыкрык аша бергә юл тоталар
Алабута үскән кырларга.

Килү белән, кайчан төш җитә дип,
Шактый гына җирләр узалар,
Тамак ялгап алгач, ничә көндә
Эш бетәсен фараз кылалар.

Яулыкларын артка читләп бәйләп,
Кояш нурларында каралып,
Көне буе эштә, таш ваткандай
Кайтып килә алар таралып.

Көнли-көнли эшләп бер-берсеннән,
Нормаларын кызлар тутыра.
Их, котылдык, диеп, чүп үләннән,
Чөгендерләр гөрләп утыра.

## ИХ, ДУСКАЕМ, ЯЛГЫШМА

Авыр булса да тормышлар,
Үз җиреңдә гомер ит.
Комсызланып яшәмә син,
Булганына шөкер ит.

Арышлар белән сөйләшәм,
Кайтсам туган ягыма.
Туган җирне ташлап китеп,
Их, дускаем, ялгышма.

Бәхетсезләр читтә яшәр,
Аерылып иленнән.
Сүнеп барган авылларны
Кем коткарыр үлемнән?

Илнең күге булсын аяз,
Басуларда — икмәкләр.
Күңелләрдә сөю булсын,
Тулып торсын келәтләр.

## АВЫР УЙЛАР КҮБРӘК КЕРӘДЕР

Атлап киләм авыл урамыннан,
Нинди тынлык, нинди рәхәтлек!
Аклык белән тулы бу җирләрем
Тәннәремә бирә сихәтлек.

Якыная барсам каласына,
Өши башлый күңел нигәдер.
Аңлый алмыйм, ник соң бу кадәрле
Җирләре дә аның үзгәдер?

Каралыкта барча җир өсләре,
Бәлки шуңа җаным әрнидер.
Шуңадырмы газиз башларыма
Авыр уйлар күбрәк керәдер.

## ҺАЙ, БУ КАРТЛЫК ХӘЛЛӘРЕ

Бар иде бит яшь чакларым,
Картайдым шул, картайдым.
Һаман дөнья куа торгач,
Алҗыдым, хәлдән тайдым.

Җитез идем, көчле идем,
Арыслан кебек идем.
Дилбегә кактырмый торган
Бер дигән егет идем.

Берсе идем сабантуйда
Мәйдан тоткан ирләрнең.
Хәзер инде чыдап булмый
Сызлавына билләрнең.

Урынга барып ятсам да,
Йокы керми күземә.
Бер-бер сүз башласам, кем дә
Колак салмый сүземә.

Тынам да, узган гомерне
Ятам искә төшереп.
Йөргән вакытларым була
Аягүрә төш күреп.

Шундый сәер халәтемне
Башкалар сизә микән?
Вакыты җиткәч, картлык ул
Һәркемгә килә икән.

Ә син, яшьлек, туктап калма,
Дәвам иттер юлыңны.
Соңарганчы, бәхилләшеп
Сузам сиңа кулымны.

Газраил дигән явыздан
Кем соң качып котылган?
Тик картайсаң да, үләсе
Килми икән, чукынган!

## НИК ИШМӘДЕМ ИКӘН ТАШЛАРЫМНЫ?!

Шигырьләрем кебек шаулап ага
Язгы сулар таудан кырларга.
Тауларыңның ташларына хәтле
Агып китәр сыман суларга.

Күзәтәмен зәңгәр чәчәкләрнең
Кар астыннан калкып чыкканын.
Кояш нурларына үрелеп лә
Тау сыртына юллар тотканын.

Карлы тауның өсләренә менеп,
Һичбер кайчан карап туймассың.
Табигатьнең чиксез матурлыгын
Күңелләр дә безнең җуймасын.

Шундый гүзәллекне күрми торган
Таш йөрәкле адәм затлары!
Нишләттегез тауны, меңнәрчә ел

Тыныч яткан ташын актарып?

Тынычлык юк миндә, һәм булмас та,
Нәфрәт хисе кайный йөрәктә.
Хөкем итеп булса «андыйларны»,
Армас идем, күпме йөрсәк тә.

Ишетәмен бичара тавымның
Ераклардан сыкрап елавын,
Бетеп бара торган урманнарның
Үзәк өзгеч ярсып шаулавын.

Кискән чакта тауның итәкләрен,
Актарылып калды ташларым.
Бульдозерның пычак асларында
Калдылар бит сылу талларым.

Ник ишмәдем ташларымны, диеп,
Әйтерсең тау шулай күрсенә,
Табигатьтән вәхшиләрчә көлгән
Явызларның төбәп өстенә.

## КАПЛАМАСЫН КАРАЛЫК

Бертуктамый карлар ява,
Җир төренә аклыкка.
Тоташырга омтыла ул
Офыктагы пакьлеккә.

Мәчет манарасын энҗе
Сарган кебек күренә.
Бар тирә-як моңлы азан
Тавышына күмелә.

Тик кышның да була хәйран
Көйсезләнгән чаклары.
Юеш яңгырлар явып,
Юып китә ак карны.

Болыттан соң куе томан
Томалый җирен, күген.
Үзебезнең хәлебез дә
Нәкъ шуңа охшаш бүген.

Кичтән беребез дә белми
Иртән ниләр буласын.
Кем үзгәртер уңай якка
Тормышның бу йоласын?

Адашмыйча, дөрес яшәү
Юлларын кем өйрәтер?
Бу хакта инде, чынлап та,
Уйланырга кирәктер.

Бәлки, табигать тә шуңа

Кисәтәдер алдан ук:
«Күпме яшәргә уйлыйсыз,
Вәгъдәләргә алданып?»

Бергәлек таулар күчерә,
Көн итмәгез таралып.
Гөлләр күкрәп үсәр җирне
Капламасын каралык.

## АВЫЛ ЭЧЕП ЮАНА

Бар дөньяның матурлыгын
Шәраблардан күрәләр.
Махмырлардан акча эзләп,
Өйдән өйгә керәләр.

Аракыга акчаны шул
Кайсы сорый үтенеп.
Башлар чатный, чыдап булмый,
Әй йөриләр бетенеп.

Кайберләре тыныч кына
Баскан җирдә торалмас.
Йодрыкларын уйнаклатып
Сугарга күп сорамас.

Бирми кара шул чагында,
Аждаһадан калышмас.
Сине түгел, анасын да
Дөмбәсләүдән тартынмас.

Бу хурлыктан хәсрәтләнеп,
Түзеп яши әниләр.
Йа Ходайның каргышы, дип,
Зар елыйлар әбиләр.

Алмагачны кочып яткан
Исерекне уятма.
Файдалары тимәс инде,
Сүзләр белән юатма.

Көн дә эчеп йөргән иргә
Табыла бит көйләүче.
Тормышын да кызганмыйча,
Гомерлеккә бәйләүче.

Айлы манара өстеннән
Ак болытлар агыла.
Кичке азан моңнарына
Әрләш, тиргәш сарыла.

Әйтерсең лә бу авылның
Кыйбласы югалган.
Эчкечелек алып узган,
Хәмер белән юылган.

Сәрхуш иттем авылны, дип,
«Яшел елан» куана.
Йа Ходаем, ни хәл итик,
Авыл эчеп юана.

## ЧАҢ СУГАРГА ВАКЫТТЫР

Һәркемнең дә туып үскән
Газиз туган ягы бар.
Язмышына буйсынып ла
Яши торган җире бар.

Туган авылым Иштирәк,
Булсак иде гел бергә.
Гомер юлым синең белән
Бәйләнгәндер гомергә.

Юл читенә тезелгәннәр
Юкәләр, өрәңгеләр.
Шат елмаю йөзләрендә,
Уңгандыр бәрәңгеләр.

Якын синең тугайларың,
Урман эчендә алан.
Әйтерсең лә урманнары
Авылны чолгап алган.

Шифалыдыр чишмәләре,
Йөз яшьлек имәннәре.
Истә калган, курорт кебек
Урын бу, дигәннәре.

Кайсы гына төбәкләрдән
Кемнәр генә килмәгән.
Кымыз эчеп, сихәтләнеп,
Яллар итеп китмәгән.

Бөтенесе юкка чыкты,
Җимерелде, тапталды.
Химкомбинат гигантының
Аяк астында калды.

«Тунгуч» дигән бер нәрсә бу,
«Тунгуч» түгел, «тонгыч» ич.
Химкомбинат калдыкларын
Чистартып тора, имеш.

Агып килгән бөтен «зәһәр»
Корытты миләшемне.
«Үле» елга итте минем
Сай сулы инешемне.

«Үле» елга аккан чакта,
Авылдашлар ут йота.

Кәрәкәс, Бигеш, Карман аша
Зәй суына юл тота.

Бу суны хәтта малларга
Эчертергә ярамый.
Каз-үрдәкләр йөзеп йөри,
Ярамыйга карамый.

Зәй кушыла Чулманына,
Чулман суын эчәбез.
Шуңадырмы бик вакытсыз
Дөньялардан китәбез.

Бәлки, шуңа күрәдерме
Күпме кеше авырый?
Фән белмәгән чирләреннән
Табиблар да аптырый.

Соңармыйча бу хәлләргә
Чаң сугарга вакыттыр.
Афәтләрне булдырмаска,
Хак Тәгаләм, ашыктыр.

## САГЫНЫРСЫЗ АВЫЛЛАРНЫ

Гомер буе каһәрләнеп
Авыл халкы яшәде.
Нинди генә авыр чорлар
Башларыннан кичмәде.

Колхозлашу елларымы,
Ельцин реформалары.
Авыр хәлләргә калдырды
Базар икътисадлары.

Иң эшлекле, иң булдыклы
Бәндәләргә каныкты.
Кулак дигән исем тагып,
Себерләргә озатты.

Әйтерсең лә көтеп яткан,
Куштан, ялкау уянды.
Кеше язмышлары белән
Алары да уйнады.

Бүген тагын андыйларның
Сүзләре өстен йөри.
Билен бөгеп, тирен түккән —
Тормыш арбасын сөйри.

Гадел хезмәт кешесенең
Бармы хәлен аңлаучы?
Әллә инде аңламыйча,
Гел кагыплар торучы.

«Миллионер» булган колхоз
Телгә алып макталмый.
Исем үзгәрткәнгә карап,
Һич кенә дә мантымый.

Теләсәң-теләмәсәң дә,
Дәүләт куйган бәяләр.
Шундый түбән бәяләрдән
Хуҗалыклар көяләр.

Миңа калса, бу гамәлләр
Махсус эшләнә икән.
Җир кешесен җирләреннән
Биздерү өчен микән?

Кырларында игеннәрең
Уңса да, уңмаса да,
Аның барыбер файдасы юк,
Булса да, булмаса да.

Җитештергән итең, сөтең
Хөкүмәтнең кулында.
Кыйммәтләнеп җиткәч кенә,
Пәйда була табында.

Их, бу алдау-йолдауларның
Иге-чиге булырмы?
Бу дөньялар һаман шулай
Үзгәрешсез калырмы?

Авылларны яшәтергә
Түрәләр уянсыннар.
Соңармыйча җитди эшләр
Хакында уйлансыннар.

Без дә берчак, зарланмыйча,
Алга атларбыз әле.
Галуш-бутыйларны да бер
Салып ташларбыз әле.

Колхозчыны сөендереп,
Газлар керә һәр өйгә.
Малын асрый, итен сата,
Яшәп ята бер көйгә.

Салалардан калаларга
Асфальт юллар тоташа.
Калкып чыккан яңа йортлар —
Үзләре бер тамаша.

Әй бу ферманың юллары
Бигрәкләр дә бормалы.
Эше дә күп, ашы да бар,
Тик йокылар чамалы.

Шәһәр халкын йоклый диләр,

Хаклык бармы сүзләрдә?
Эшлим дисәң, эшләре юк,
Сагыш тулы күзләрдә.

Авылдан бер китәрмен дип
Уйланып йөрүчеләр,
Сагынырсыз, авылларны
Калдырып китүчеләр.

## ГАЛӘМГӘ ЧАҢ КАГАСЫ!

Әй машина, машина, син
Чит илнеке булсаң да,
Берәүнең дә исе китмәс,
Шаккатырып узсаң да.

Һаман саен синдә генә
Йөрүләре туйдырды.
Ни хәл итик, бу заман да
Безне атсыз калдырды.

Иртә таңнан, атлар җигеп,
Чыгып китәсе иде.
Басу юлларын уратып,
Кайтып киләсе иде.

Тарантаслы, яхшы юртак
Килеп туктаса турыга,
Шул минутта бар дөньясы
Күмелер кебек нурга.

Әткәй-әнкәй, күрше-күлән
Хәйран калып гәпләшсен.
Тамашадай бу хәлләрне
Бөтен авыл сөйләшсен.

Көннәр түгел, хәтта айлар
Сарыфлар ителсә дә,
Җигүле ат булсын иде,
Еракка кителсә дә.

Кичәр өчен дәрьяларны,
Узар өчен юлларны,
И Ходаем, ярдәмеңнән
Ташлама син атларны.

Бар җиһанны иңләп йөрсен
Ярсу атлар, ыжгырып.
Тарантаслар тәгәрәсен,
Тузаннарны туздырып.

Шауласын тояк тавышы,
Очкын чәчсен дагасы.
Саклагыз сез атларны, дип,
Галәмгә чаң кагасы!

## ШӘРӘ ЙӨРЕРЛӘРГӘ КАЛМАСАК...

«Күрәчәгең булса, күрерсең», — дип,
Борынгылар юкка әйтмәгән.
Мескен хәлгә калган бу Рәсәйне
Кемнәр генә ташлап китмәгән.

Алыпсатар, чималларны сатып,
Ил байлыгын ничек кимерә.
Таланган һәм хуҗасыз илебез
Нинди авыр хәлләр кичерә?

Эшсезләрнең саны арта бара,
Чит илләрдән бер дә калмыйлар.
Чарасыздан, ни эшләргә белми,
Көпә-көндез кеше талыйлар.

Гадел хезмәт иткән җаннарның шул
Соңгы каурыйларын йолкыйлар.
Кәкре куллы, урлап туймас затлар,
«Йолдыз» сыман, җирдә балкыйлар.

Илнең-көннең сүлен суыралар,
Дөньясына алар төкерә.
Тәм-ләззәтләр табып яшәүләрдән
Әйтерсең лә айга сикерә.

Хәрам хәзинәгә чума-чума,
Бер иш байлар яши типтереп.
«Хет бәрәңгем үземнеке», — диеп,
Авыл халкы йөри тилмереп.

Кала халкы йөрми мунчаларга,
Корчаңгы, бет басты тәннәрне.
Кем уйлаган пычракка күмелеп
Адәм заты яшәр көннәрне.

Кунак төшү, ихлас елмаюлар,
Көр тавышлар кая киттеләр?
Җиһаз-бизәк, кием-салымнардан
Кешеләрне мәхрүм иттеләр.

Киләчәктә мондый хәлләрдән без
Чыгу җаен әгәр тапмасак,
И Ходаем, бәндәләрең белән
Шәрә йөрерләргә калмасак...

## ЯШИБЕЗ ҖАЙЛАП КЫНА

Авылыма кайткан саен
Китәм яңалык белеп:
Халык хезмәт хакы алган
Моннан ел ярым элек.

Өйдән өйгә, йорттан йортка
Әҗәт сорап керәләр.
Мал-туар тотучыларны
Әллә каян беләләр.

Авыл халкы кешемени,
Ул бит Хода бәндәсе.
Бер ризыксыз яшәүнең дә
Җаен белә, янәсе.

Кала кешеләренә дә
Җиңел түгел, әлбәттә.
Анда да теләнеп яшәү
Кергән инде гадәткә.

«Авыл яшәсә, ил яшәр» —
Еш әйтелә шул сүзләр.
Илне сөйрәп барган авыл
Үзе соң ничек түзәр?!

Еллар буе өндәделәр
Колхозны яратырга.
Хәзер инде ничек итеп
Белмиләр таратырга.

Аларны бит мескен хәлгә
Калдырдылар түрәләр.
Ә үзләре шул колхозлар
Сыртында көн күрәләр.

Фермер-фермер, дигән булып,
Әллә ниләр сөйлиләр.
Тик аларның ни эшләргә
Тиешлеген белмиләр.

Эт көнендә яшәүләрнең
Булырмы берәр чиге?
Кая китә ил байлыгы,
Шуны беләсе иде.

Урман-болын һәм җир-сулар
Күчә кемнәр кулына?
Байлар бүлә улларына,
Улларының улына.

Киләчәкне уйлап, халкым,
Зиһеннәрең таркалган.
Алгы көндә нинди язмыш
Элеп алыр якаңнан?

Бу гаделлек, бәлки, бардыр
Дөньяның кай илендә...
Юк, аны таба алмассың
Канлы Рәсәй җирендә.

Әрәмгә көч сарыф итеп,

Ничу эшләп йөрергә.
Алыпсатарлар һөнәрен
Кирәк үзләштерергә.

Колхозлар тарала, диләр,
Ник төшәргә кайгыга?
Чит илләрдән кайтып тора
Сөте, ите, мае да.

Мәскәүдән кушканны үтәп
Яшибез җайлап кына.
Депутатлар җибәрәбез,
Иң шәбен сайлап кына.

Алар нәрсә кылса, шуның
Барысына түзәрбез.
Сайлау арты сайлау ясап,
Күпме акча түгәбез.

Яртылаш та үтәлмиләр
Указ, карар, законнар.
Ник бу эшне үз кулына
Алмый икән хатыннар?!

## МЕНӘ ШУНДЫЙ ЗАМАН ҖИТӘР

*(Бәет һәм мөнәҗәтләргә ияреп)*

Тыйлыкмас гомер җилләре,
Сизелмәс картлык килгәне,
Юатмас бәхет дигәне,
Менә шундый заман җитәр...

Эшләп-эшләп, эшең бетмәс,
Тамагыңнан ашың үтмәс,
Күзләреңнән яшең китмәс,
Менә шундый заман җитәр...

Тормышыңның яме булмас,
Ризыгыңның тәме булмас,
Башкаларда гамең булмас,
Менә шундый заман җитәр...

Галәм халкы азар-тузар,
Җирнең тынычлыгын бозар,
Дус дигәнең таптап узар,
Менә шундый заман җитәр...

Хатын-кызлар хәмер эчәр,
Ир-атларыннан ваз кичәр,
Сабыйларын ятим итәр,
Менә шундый заман җитәр...

Яшүсмерләр азган булыр,
Остазлары надан булыр,
Вәгазьләре ялган булыр,

Менә шундый заман җитәр...

Ир-атларда гайрәт бетәр,
Хатын-кыздан оят китәр,
Изге гамәл һич кылмаслар,
Менә шундый заман җитәр...

Түрәләр гел биек үрләр,
Даулашып тәхеткә менәр,
Йорт-җирен алтынга күмәр,
Менә шундый заман җитәр...

Байларда мәрхәмәт калмас,
Бирсәң, сәламеңне алмас,
Гозереңә колак салмас,
Менә шундый заман җитәр...

Туганнардан миһербан качар,
Җаннарын хөсетлек басар,
Явызлыклар хәттин ашар,
Менә шундый заман җитәр...

Күңелләрдән шәфкать китәр,
Өлкәннәргә хөрмәт бетәр,
Гомерләр заяга үтәр,
Менә шундый заман җитәр...

...Менә шундый заман җитәр,
Исебездә тотыйк барсын.
Изге гыйбадәтләр кылыйк,
Иманыбыз исән калсын.

## ОКТЯБРЬ БӘЙРӘМЕНДӘ

Октябрьнең бөек бәйрәмендә
Күпме шатлык иде өйләрдә.
Кайчан гына килеп җитәрсең дип,
Көтә идек сине көзләрдә.

Килә идең безнең йөрәкләргә,
Ялкын өстәп, шатлык өләшеп.
Чит илләрнең «оҗмах кошлары» да
Карый иде сиңа көнләшеп.

Көнләшерлек: халкың, бердәм булып,
Урам, мәйданнарга агыла.
Җилфердәтеп җилләр байракларны
Көмеш быргыларга кагыла.

Их, тарала иде бу бәйрәмдә
Күңелләрнең барлык сагышы.
Һәм кушылды быргы тавышына
Дәртле җырларыңның агышы.

Якты уйлар, өмет чаткылары

Чагыладыр көләч йөзләрдә.
Көр авазлар белгертәләр иде
Бәйрәм килгәнлеген күзләрдә.

Ул кунакка төшү, очрашулар,
Кавышулар күпме булгандыр;
Бөек илнең балалары идек,
Сагынырга гына калгандыр.

Партиянең әйткән өндәмәсен,
Кушканнарын эшләп өйрәндек.
Ни булды соң безгә, нишләдек без?
Фатирларга кереп бикләндек.

Бикләндек шул, башка беркемгә дә
Ышанычы аның калмагач.
Илдә барган «бөек» үзгәрешләр
Гади халкың өчен булмагач.

Гомер уза, ә без бикләнәбез,
Күңелләрдә — әрнү, ачыну.
Гаделсезлек алып узган җирдә
Ничекләр соң басыйк ачуны?

Халкыңны син упкыннарга илтеп,
Йолып алалмасаң бәладән,
Ватан дигән изге сүзләр кабат
Кайтыр микән инде яңадан?

Ял артыннан яллар килеп тора,
Бәйрәмнәр күп, әмма сизелми.
Яшәгән бит авыр чорларда да,
Бәйрәмнәрдән бер дә бизелми.

Ник талпына әле бу күңелем,
Үткәннәрен әллә сагына?
Урамнардан кабат «Ура!» диеп,
Бер узасы иде тагын да!

Көзләр җиткәч, нидер көтәм һаман,
Кайтыр сыман безнең ул чаклар.
Йөрәкләргә дәрт-дәрманнар өстәп,
Бер кабыныр кебек учаклар.

## ӘЙ БУ БАЗАР ХӘЛЛӘРЕ

Рәт аралары тардыр,
Басып тора иренми.
Берсе килә, берсе китә,
Саткан әйбер күренми.

Җайлы, матур сүзләр белән
Үз ягына тиз бора.
Кирәк чакта сатулаша,
Сүзендә дә нык тора.

«Тиз юыла, югач, төсен
Һич үзгәртми, җаным, — ди. —
Мондый хакка башка җирдән
Табалмассың тагын», — ди.

Ирләргә хас уртак сыйфат
Күбесен берләштерә.
Бераз гына «кабып» алгач,
Төрлесен сөйләштерә.

Карлы буран, җил-яңгырда
Туры килә чыдарга.
Бу эшсезлек, кыскартулар
Ирексездән чыгара.

Күпме һөнәр ияләрен
Үз эченә ала бит.
Яхшы табиб, мөгаллимсез
Күпләребез кала бит.

«Базар» дигән шул хикмәтне
Кемдер, бәлки, хуплыйдыр.
Хатын-кызның гүзәллеген,
Матурлыгын урлыйдыр.

## И ТУГАН ҖИРЕМ...

Их, үтәсе иде басу буйлап,
Гармун уйнап, «Алмагачы»н җырлап!
Тынып калыр иде сайравыннан
Сандугачлар, безнең җырны тыңлап!

Туган якның җилләре дә якын,
Битләремнән назлап сөяләр!
Туган җирем, кырларыңда синең
Тук башаклар башын ияләр.

Шушы җиргә, шушы туфраккамы
Гомер буе без бит бурычлы.
Бурычларны үтәп булыр микән?
Кырыс заман киде — «борычлы»!

## ЯКТЫ КӨННӘРЕҢӘ ҖИТӘРСЕҢ

Көч һәм сәләтеңне эшкә җигеп,
Хаклык эзләп азмы янмадың?!
Әмма ничек кенә тырышсаң да,
Хакыйкатьне таба алмадың.

Тузаннарын йотып дәверләрнең,
Актарасың тарих битләрен.
Табалмыйсың тирән яшерелгән

Сандыкларның серле бикләрен.

Әйтерсең лә шулай бар дөньясын
Басып киткән этлек-явызлык.
Баш бирмәгән кара явызлыкка
Кидерәсе иде авызлык.

Дөреслек һәм хаклык — яралы кош,
Очарга дип канат талпына.
Бәйсезлегең өчен күтәрел, дип,
Оран сала туган халкыма.

Уяулыгың җуйма... Шунда гына
Киртәләрне җимереп үтәрсең.
Һәм гасырлар буе хыялланган
Якты көннәреңә җитәрсең.

## НӘРСӘ БУЛДЫ СИҢА, РУСИЯ?..

Күнегелгән иде, Рәсәй, сине
Көчле һәм бай ил дип санарга.
Көтмәгәндә шундый мескен хәлгә
Төшүеңне ничек аңларга?

Кайчан гына әле синең белән
Исәпләшми иде кем генә.
Хәзер үзең барып тезләнәсең
Башкаларның ишек төбенә.

Шул юл белән черек нигезеңне
Ныгытырга, ахры, уйлыйсың.
Ирек таләп иткән милләтләрнең
Язмышлары белән уйныйсың.

«Бүленмәс һәм бердәм Русия», — дип
Әйтерлегең бармы мактанып?
Сизмисеңме әллә барганыңны
Бөтенләйгә инде таркалып?!

Үз халкыңны хәтта туйдырырга
Килми бүген синең кулыңнан.
Белмим, исән-имин чыга алырсыңмы
Һәлакәткә илткән юлыңнан.

## КЕМ СОҢ ТИЕШ?

Еллар буе ал-ял белмәсәк тә,
Түрәләргә бер сүз дәшмәдек.
Бил тиңентен пычрак-сазлык ерып,
Матур тормыш көтеп яшәдек.

Килдеме соң көткән ул замана,
Борылып кара тирә-ягыңа,
Шул ук михнәт, шул ук гаделсезлек

Басып тора һаман алдында.

Элек тигез гомер иткән кешеләр
Байлар, ярлыларга бүленгән.
Газиз аналарның керфегенә
Кайнар күз яшьләре эленгән.

Тик барыбер безнең күзләребез
Текәлгәннәр килер елларга.
Күнеккәнбез тормыш авырлыгын,
Кайгыларны җиңеп чыгарга.

Өйрәнмик без бу дөньяга бары
Алсу күзлек аша карарга.
...Кем соң тиеш җирнең иңнәренә
Керләнмәгән ак шәл ябарга?!

## ЗАМАНАЛАР БИГРӘК АВЫР, ДИЕП...

Заманалар бигрәк авыр, диеп,
Җитәр инде, күңел, көрсенмә.
Кемдер килеп төзәтмәде әле
Безнең ялгышларның берсен дә.

Бөтенесе үзебезгә бәйле,
Бүгенгебез, туар көнебез.
Йолдызларны сөеп яшәү кирәк,
Якты булсын дисәк күгебез.

Ә кем әйткән сиңа, бу заманда
Көн итүләр җирдә җиңел, дип?
Юккамыни соң без олауларга
Йөк атлары булып җигелдек.

Үзебез тартыйк, үзебез сөйрәп барыйк
Замананың авыр йөкләрен.
Бергәләшеп игик, эшләп ашыйк
Кара җирнең хәләл икмәген.

Туган-үскән җирне сөюебезне
Изге маяк итеп яндырыйк.
Бәрәкәтле буразнага чорның
Саф орлыгын чәчеп калдырыйк.

## ЙОМЫШЫҢ ТӨШӘ КАЛСА...

Кайберәүләр көн итәләр
Тынчу-кысан йортларда.
Тик барыбер аһ ормыйлар,
Чәпченмиләр юк-барга.

Саф һавага туймыйбыз, дип
Зарланмыйлар кич-иртә.
Ишегалларына чыгып

Җилләнүгә ни җитә!

Шуңа мәллә андыйларның
Кәефе яхшы булыр.
Күңелләре күтәренке,
Йөзләре якты булыр.

Ә бер иш бәндәләр яши,
Һәрнәрсәдән шикләнеп.
Күрше-күләннәрдән качып,
Бүлмәсенә бикләнеп.

Ишек ачуларын көтмә,
Йомышың төшә калса.
Рәхмәт, диярсең, урамда
Биргән сәламең алса.

Шундыйлар янында ничек
Кеше исемен саклыйсы?..
Ә бит безгә бу дөньяда
Бер үк юлдан атлыйсы.

## ӨМЕТ БЕЛӘН ЯШИК

Гомер итүләре кыен, диеп
Боекма син, күңел, боекма.
Җитәр вакыт, бер таралыр әле
Күкне каплап алган болыт та.

Уйга китермәгән идек тә бит
Мондый авыр көннәр килер дип:
Кемдер майда йөзә, ә кемнәрдер
Ятлар күзенә карый тилмереп.

Тормыш йөге баскан халкым әнә
Бүген нинди хәлләр кичерә...
Заман кыса безне чытырдатып,
Түзеп кара аның көченә.

Бирешмик, әй, өмет белән яшик,
Ташламасын безне сабырлык.
Күңел гөлебезне яшәртергә
Бардыр әле җирдә саф орлык.

## ХАФАЛАНМЫЙК ӘЛЕ

Талгын гына исә июль җиле,
Бар җиһанны назлап-иркәләп.
Хәбәр итеп урак эшләренең
Башлануын быел иртәрәк.

Якын дустым, шуны белгән кебек,
Син дә кайтып төштең авылга.
Малай вакытларны искә алып,

Бер гәпләшик әле тагын да.

Уйлап баксаң, күпме гомер узган,
Биш дистәне кичтең кай ара.
Без ат көткән аланнарда хәзер,
Бездән качып, яшьлек шаяра.

Юк, белмичә әйтмәгәннәр икән
«Үткән гомер — агымсу кебек».
Телик, дустым, кылган ялгышларга
Яшәмәсәк иде үкенеп.

Бу дөньяда без бит кунак кына,
Хафаланмыйк әле юк-барга.
Гашыйк булып яшик әле һаман
Еракларда янган утларга.

Артка борылып карап, офтанырлык
Эшләрең юк үткән юлыңда.
Баһадирдай уллар үстергәнсең,
Җир язмышы алар кулында.

Машинаңда синең белән бергә
Нинди генә җирләр гизмәдек!
Онытылмас уйлар кочагында
Арыганлык, алҗу сизмәдек.

Гаярь булып кал син тормышыңда,
Канатларың талу белмәсен.
Бөркет кунган горур кыяларның
Иң-иң биегенә үрлә син.

Егерменче гасыр узып бара,
Шул гасырның без бер баласы.
Гомер узган саен, киләһаман
Җир малае булып каласы.

## ҺАМАН ЮЛДА

Юл-сукмаклар салып алга барам,
Һич үткесез шушы юллардан.
Берничек тә котылып булмас кебек
Яңа явып үткән карлардан.

Мин гел юлда, үткән юлларымда
Яңа эзләр кала салынып.
Исән-имин йөреп кайтыр өчен
Ходаемнан сорыйм табынып.

Күз ачкысыз кышкы бураннарда
Бик күпләр бит әле адашкан.
Гел аклыктан торган җиребез дә
Офыкларга килеп тоташкан.

Җилләр улый, җилләр ыжгыра ул,

Үзәкләргә үтә суыклар.
Кар каплаган Ишкәй күлләрендә
Тыныч кына йоклый балыклар.

Кешеләр дә тыныч булсын иде,
Кайгы җиле өйгә кермәсен.
Кар-бураннар тормыш сукмакларын
Берүк каплап китә күрмәсен.

## БАЛКЫСАҢЧЫ РӘСӘЙ КҮГЕНДӘ

Аңлый алмыйм, нәрсә булды сиңа,
Нинди мескен хәлгә калдың син?
Бай Рәсәйдән ничек шушы тикле
Бөлгенлеккә төшә алдың син?

Бар иде бит синең дәүләтләрне
Дер селкетеп торган чакларың.
Туганнарга ярдәм итәм, диеп,
Кая гына аяк басмадың.

Ачтан үлмәс өчен хәзер үзең
Чит илләрдән ярдәм сорыйсың.
Үз байлыгың үзеңнеке түгел,
Таулар булып өелә бурычың.

Сабырлыгын җуя барган халкың
Алга таба ничек чыдасын.
Белмим, Рәсәй, нәрсә көтә сине,
Бу хурлыктан ничек чыгарсың?

Рәсәй кичергәнне кичерергә
Туры килмәс димә безгә дә.
Татарстан, ятлар алдында син
Хәер-ярдәм сорап тезләнмә.

Тик шулай да әле язмышыбыз
Шомландыра никтер бүген дә.
Татарстан, якты йолдыз булып
Балкысаңчы Рәсәй күгендә.

## УЯНЫРГА КИРӘК, ХАЛКЫМ!

Алып китә кайчак безне юллар
Күз күрмәгән ерак илләргә.
Язмыш җиле тартып кайтарадыр
Кендек каны тамган җирләргә.

Үз иленнән чит җирләргә китеп,
Нинди эшләр соң ул майтара?
Таш бәгырьле бәндәләрен хәтта
Туган җирләр тартып кайтара.

Шундый сихри көчкә ия булган
Андый җирләр тагын бармы соң?
Урман-сусыз калып барса да бит,
Нинди якын икән Туган җир!

Шушы газиз җирем афәтләрне
Үз башыннан күпме кичерде?
Инде калган соңгы урманнарын
Юк итәргә боерык бирелде.

Имеш, зыян салмый торган чиста
Яңа завод монда булачак!
Тагын шундый ук химия гиганты
Агу бөркеп җиргә торачак.

Әллә инде җире каһәрләнгән —
Каныктылар шул бер урынга!
Әйтерсең лә башка берәр җирдә
Урын юктыр завод корырга!

Эшли торган заводлары әле
Күпме зыян безгә китерә!
Яңалары беркөн эшләп китсә,
Тере килеш утта көйдерә!

Калабызны күксел томан каплый,
Тончыктыргыч агу тарала.
Яңа явып үткән ап-ак карлар
Җиргә төшмәс борын карала.

«Үле елга» булып, инешкәем,
Кай якларга агып китәсең?
Суларың да синең — зәңгәр агу,
Йә, кемнәргә бүләк итәсең?

Безгә булмый, кемгә булсын инде?
Килеп кушыласың Зәйләргә.
Ә Зәйләре Чулманына коя...
Шул суларны эчеп яшәргә!

Бу җирләрдә ничек көн күрергә,
Алга таба ничек яшәргә?
Шул химия «шифалары тия»
Кырау сугып япь-яшь ирләргә.

Ялгыз түгел, ирле хатынның да
Күз яшьләре бүген коела.
«Кая бу чын ирләр?» дигән аваз
Гадәти хәл булып тоела.

Җитәр, халкым! Күпме була түзеп?
Гомерләрне йоклап уздырмыйк!
Изсәләр дә изелмәдек әле,
Уяныргa кирәк — соңармыйк!

Ул авыру, эшкә яраксызлар

Һаман саен артып бара бит.
Нинди чир соң бу, дип, табиблар да
Уйланып ла кайчак тора бит.

Их син, халкым, тик соңармый гына
Күтәрелеп әгәр чыкмасак,
Түбән Кама каласында без бит
Үле җаннар булып калачак.

Килер бер көн, хөкем итәр Ходам,
Тик ялгышмыйк берни булмас дип
Тереклек һәм Җирнең рәнҗешләре
Өстебезгә төшми калмас дип!

## АРТЫГЫН КӨЧӘНМӘГЕЗ

Үз оясын корып яши
Җирдә һәрбер тереклек.
Тик яшисе гомер генә
Узмасын үкенерлек.

Һәрбер корылган нигезләр
Нык булсын, какшамасын.
Сынауларда сынатмасын,
Беркайчан таркалмасын.

Эшмәкәрләр шул нигездә
Җир җимертеп көн күрә.
Алны-ялны белмәгәнгә,
Байлык ишелеп керә.

Ары чаба, бире чаба,
Дөнья артыннан куа.
Куып җиттем дигәч кенә,
Картлык бугаздан буа.

Картайса да, бер ишләре
Йөри эшләр майтарып.
Кодрәтле яшь чакны гына
Булмый икән кайтарып.

Нидер кирәк, нидер җитми
Бу адәм баласына.
Булганына шөкер ит син,
Борчылма булмасына.

Җитәр инде, йөрмә шулай
Байлыкларга алданып.
Иманга кил, намазга бас,
Күп йөрдең бит адашып.

Бер-бер авырлык килгәндә,
Ходайга табынабыз.
Күпме тәүбәгә килсәк тә,
Яңадан абынабыз.

Ике гомер яшәрдәй күк
Көнләшеп көн күрмәгез.
Кала бит ул дөнья малы,
Артыгын көчәнмәгез.

## ЕРАКЛАРГА ТОРЫР КҮРЕНЕП

Мәчет әйткән: «Ни зарарым тиде,
Манарамны нигә күрәсез?
Күңелләргә якты нур иңдергән
Айсыз торып калгач нишләрсез?»

Акрын гына күккә ашкан мәлдә,
Тәңрем аны үзе зурлаган.
Канатларын җилпеп, фәрештәләр
Иң саф теләкләрен юраган.

Тормыш агышында язмыш шулай
Дин йортыннан барысын күпсенгән.
Манарасын кисеп төшергәндә,
Җилләр булып җилләр үксегән.

Үксегәннәр мөэмин-мөселманнар,
Тәрәзәләр төшкән коелып.
Һәр тарафта дога укылганда,
Бөтен җиһан калган боегып.

Ояларын кошлар ташлап киткән,
Ләгънәт укып кансыз затларга.
Ярдәмең бир, Ходаем, бәндәләргә
Ата-баба рухын сакларга.

Кыргый замананың гөнаһлары
Рәнҗетмәсен изге җаннарны.
Җирне кочкан азан моңнарыннан
Мәхрүм итмә берүк аларны.

Гаделсезлек туй иткәнен күреп,
Кешеләрнең бәгъре кыйнала.
Соңгы өмет белән карашларын
Юнәлтәләр алар кыйблага.

Җирдә аунап яткан манараның
Бәддогасы төшәр кемнәргә?
Кемнәр шакшы кулын суза шулай,
Фәрештәләр кунган мөнбәргә?

Юк, уйга да алар китермиләр
Иман кире кайтыр көннәрне.
...Дин йортлары кабат калкып чыга
Сөендереп җирдә меңнәрне.

Милләт күңелендәге изге хисләр
Беркайчан да калмас күмелеп.

Мәчетләрнең айлы манарасы
Еракларга торыр күренеп.

## САБЫРЛЫКЛАР СОРЫЙК ХОДАЙДАН

Син бит, авыл, инеш-күлләр ягы,
Зәңгәр булып сулар агадыр.
Тормыш бит ул гел шатлыктан тормый,
Зилзиләләр булып торадыр.

Килгән кадәр игелекләр кылып,
Сабырлыклар сорыйк Ходайдан.
Торсын иде безнең җир өсләре
Җанга якын булган җаннардан.

Җил-давыллар үтәр, сулар тынар,
Үз җаена кайтыр тормышлар.
Сынар өчен без бит яратылган,
Язмышлардан юктыр узмышлар.

## ОЛУГ БӘЙРӘМ РАМАЗАН

Олуг бәйрәм килә безгә,
Олуг бәйрәм Рамазан.
Бу изге айны олылап
Каршылыйк без яңадан.

Каршылыйк без, Коръән укып,
Салават, тәхлил әйтеп:
Җибәрик күңелләребезнең
Офыкларын киңәйтеп.

Барлык кардәш-ыруларны
Хөрмәтләп искә алыйк.
Сөекле пәйгамбәребезнең
Рухына тугры калыйк.

Тугры калыйк шәһит киткән
Изгеләрнең рухына.
Кылган догаларыбызга
Җан җылыбыз кушыла.

И туганым, кешеләрдән
Кызганма хисләреңне.
Онытма җирдә үзеңнең
Тик кунак икәнеңне.

Онытма якты дөньяны
Калдырып китәсеңне.
Кылган гөнаһларың өчен
Тәүбәләр итәсеңме?

Һәрчак биш вакыт намазың
Торсын иман сагында.

Үлемнән йолып калалмый
Байлыгың да, малың да.

Бөтенесен күңелеңнән
Кичер тагын яңадан.
Олуг бәйрәм килә безгә,
Олуг бәйрәм Рамазан.

## ТАТАР ИСЕМЕН ГОРУР ЙӨРТЕРГӘ

Кая гына сибелмәгән татар,
Кайда гына гомер итмәгән?!
Яшәгәндә чит җир туфрагында,
Күпме газап-михнәт чикмәгән?!

Татарстан, ерак-еракларда
Кемнәр генә сине сагынмый?!
Кемнәр генә сине танымый да,
Үз Ватаны итеп табынмый?!

Үзең дә бит шуңа бөтенесен
Улларыңдай якын күрәсең.
Авыр чакларында һәркайсына
Җылы сулышыңны өрәсең.

Сиңа булган сөю хисен бездән
Тартып ала алмас беркем дә.
Юккамыни сиңа сүз бирдек без
Татар исемен горур йөртергә.

## МӘҢГЕ ЯШЬ СИН

Һәр яз саен Шигырь көне килә,
Яшәргәндә кырлар-тугайлар.
Йөрәкләрдә җыр-шигырьләр туса, —
Без бурычлы бөек Тукайга.

Искә ала бүген халкым аны.
Ул шагыйрен һәрчак зурлады.
Онытмады бер дә шигырьләрен,
Моңлы җырлар итеп җырлады.

Булмасаң да, Тукай, арабызда,
Безнең белән һаман яшьнисең,
Син бит безнең күңел түрләрендә
Япь-яшь Тукай булып яшисең.

## ӘҮЛИЯ ҖАН ТАГЫН ТУАРМЫ?

Ни өчендер бөек, зур шәхесләр
«Имеш-мимеш»ләрне тудыра.
Заманында төрле гайбәт сүзне
Үз башыннан Тукай уздыра.

Денсез-динсез, Алласыз дәһри, дип,
Салкын-сүрән еллар яшәлгән.
Диннән түгел, бары азгын, надан
Муллалардан көлеп яшәгән.

Таш маңгайлы ишаннардан көлеп,
Кирәкләрен биргән камчылап.
Дингә тугры мөэмин-мөселманның
Барлаган ул барсын тамчылап.

Тукай сыман халык йөрәгендә
Тамыр җәйгән шагыйрь булырмы?
Хозыр Ильяс кебек илаһи зат,
Әүлия җан тагын туармы?

## ТУФРАККАЕН КИЛӘ ҮБӘСЕМ

Кышлар үтеп, язга керү белән
Көтә башлыйм Тукай көннәрен.
Якты апрель алып килә аңа
Халкыбызның күңел гөлләрен.

Килә минем Кырлай урманнарын
Аркылыга-буйга гизәсем.
Кендек каны тамган Кушлавычның
Туфраккаен килә үбәсем.

Барган җирләремдә эзләп йөрим,
Юлыгырмын кебек Тукайга.
Ютәлләгән тавышын чорлар әле
Ыграк ишетер язгы бу айда.

Кайтыр сыман шагыйрь арабызга,
Сөендереп бөтен дөньяны.
Чәчәк үреп шигъри юлларымнан
Каршыларымын кебек мин аны.

## САЛЫНГАНСЫҢ ИЗГЕ НИГЕЗГӘ

Алтмышынчы еллар...
Малай чагым...
Шау-гөр килә бөтен тирә-як:
Актүбә һәм Субай тирәсендә
Яңа кала үсеп чыгачак.

Авылыбыздан чыгып, урман аша
Тәпиләдек без шул якларга.
Тормыш кушкач, яңа төзелеп яткан
Баракларга карап атладык.

Шуның берсе бигрәк истә калган,
Икмәк кибете иде элек ул.
Авыр еллар иде...
Аңарчы да

Өзелмәде безнең аңа юл.

Биштәр аскан үсмер малайларны
Ачлык йөртте шулай еракка.
Ипекәйне күбрәк алыр өчен
Кат-кат баса идек чиратка.

Биштәребез яртылаштан ашкач,
Ризык заты кергәч авызга,
Атлап түгел, йөгереп тә түгел,
Очып кайта идек авылга.

Ул чагында безгә һәр яңалык
Бер могҗиза булып тоелган.
...Тормышымны башлап киткәнмен ич
Актүбәнең читән буеннан.

Яшь каланың җанлы шаһиты мин,
Горурланмый кара син шуңа.
Монда хәзер күпме милләтләрнең
Язмышлары бергә кушыла.

Меңәрләгән дусларымны таныйм,
Урамнары буйлап үткәндә.
Матурлыгын данлап туган җырлар
Мәңге тугры юлдаш күпләргә.

Шуңа да бит күңел җылысын кушып,
Рәхмәт сүзен юллый ул безгә.
Сөеп туймас калам, салынгансың
Бәрәкәтле, изге нигезгә.

Ничек сокланмассың: бөтен ягың
Хозурлана, үсә, яшәрә.
Насыйп булсын берүк гомерем буе
Синең кочагыңда яшәргә.

## ЯКТЫРТУЧЫ ЙОЛДЫЗ СИН

Кара төндә яшен ташы булып
Атылдың син илең күгенә.
Якты эз калдырган метеориттай
Кереп калдың безнең күңелгә.

Ялкынланып, янып яшәгәнсең,
Җан җылысын биреп халкыңа.
Халкың белән бергә бар кешелек
Башын ия синең каршыңда.

Давылларның ниндиләрен генә
Күкрәп узмагансың тоташтан?!
Юккамыни синең йөрәгеңне,
Җаннарыңны сагыш-моң баскан.

Япь-яшь башкаеңнан бу дөньяның
Күпме михнәтләре узмаган.
Мал-мөлкәтең түгел, үзеңнең бит

Торыр урының да булмаган.

Мәхәббәт тә синнән читтә йөргән,
Шунысы үкенечле бүген дә.
Зәйтүнәгә дигән саф хисләрең
Китеп барды микән күңелеңдә?

Кызлар белән танышудан да ул
Качып йөргән гомер буена.
Аңа гыйшык тоткан Зәйтүнәсе
Ниләр йөртте икән уенда?

Үлмәс җырлар — киләчәккә алар
Дәверләрне әйдәп барачак.
Тукаебыз милли шигърияттнең
Пәйгамбәре булып калачак.

Рухи күгебездә һәрчак шулай
Таң йолдызы булып балкы син!
Кара төндә татар халкы өчен
Яктыртучы Тукай — йолдыз син!

## ҮЗ КЫЙБЛАҢНЫ САКЛАП КАЛГАНСЫҢ

*Аксубай районындагы*
*Чәтрән авылына багышлыйм*

Ераклардан узып барган чакта
Айлы манаралар күренә.
Өч мәчетнең азан авазыннан
Бар тирә-як моңга күмелә.

Таулар куенына сыенып үскән
Каенкайлар тыңлый ул моңны.
Тал-тирәкле Сөлчә буйларыннан
Сөйкемлерәк җирләр булырмы?

Юкка гынамыни борынгылар
Нигез корган шушы урынга.
Кемнәр генә белми бу яктагы
Чәтрән атлы авыл турында.

Алты гасыр гомер кичерсә дә,
Югалтмаган үзенең кыйбласын.
Биредә син болгар бабайларның
Мәңге сүнмәс рухын тоясың.

Җырлар булып күчә күңелләргә
Көмеш чишмәләрнең чыңнары.
Килер заманнарга бара шулай
Халкыбызның изге моңнары.

## ӘНКӘЙЛӘРГӘ БУЛГАН МӘХӘББӘТ

Ямьле җәйнең июль урталары,
Аваз салып ошбу җиһанга,
Бәхет сирпеп туган йортыбызга,

Кыз туганым килә дөньяга.

Бу бәхетле мизгелләр дә беркөн
Кайгы җиле белән тулдылар.
Кинәт кенә әнкәй чирләп китте,
Борчу белән көннәр тудылар.

Әсма апа килде — авылыбызның
Иң хөрмәтле заты — докторы,
— Хәле авыр, белмим, — диде доктор, —
Калып булыр микән коткарып?..

Әткәй ул чак Пермь якларында...
Кайда йөртми язмыш кешене.
Бераз акча булмас микән диеп,
Чыгып киткән балта эшенә.

Урман артындагы бер авылда
Әби-бабайларым бар-барын.
Бер-бер төрле ярдәм итмәсләрме?
Әллә кайтыргамы соң барып?

Уттай янган битләреңне, әнкәм,
Нәни куллар сыйпап алдылар.
Һич тыелып булмый, бу күзләрдән
Бөртек-бөртек яшьләр тамдылар.

Ишеттеме? «Сау бул, әнкәм», — диеп
Пышылдадым, тотып кулыннан.
Кояш инде кичкә авышканда,
Чыгып киттем урман юлыннан.

Үзем чабам, үзем күккә багам
Һәм ялварып дәшәм Аллага:
«И Ходаем, ятим итмә безне,
Ярдәмеңнән безне ташлама!»

Атлыймын да тагын йөгерәмен,
Як-ягыма куям каранып.
Шомландырып куя агачлары,
Күз алларым китә каралып.

Чабып барган җирдән каршыма ук
Килеп чыгар кебек бүреләр.
Дөм караңгы, күзләремә алар
Күренә күк, бигрәк эреләр!

Кара төндә, кара урман аша
Әби-бабам йортын шакыдым.
«Әнкәм авырый, хәбәр бирергә дип,
Сезнең янга, — дидем, — ашкындым!»

Бусагадан яшьле күзем сөртеп,
Туктап калдым ишек төбендә.
Сөйли алмыйм, басып торам елап,
Күпме кичереш күңел түремдә!

Әби-бабай, ни әйтергә белми,
Гаҗәпсенеп карап тордылар.
«Өнме соң бу әллә төшме?» — диеп,
Маңгаемнан сыйпап алдылар.

Таң алдыннан, арбага ат җигеп,
Кузгалдык без изге сәгатьтә.
Чыгып килгән кояш нурлары да
Калды кебек яхшы теләктә.

«Әйдә, бабай, чаптыр атыңны! — дим. —
Озын әле кайтыр юлыбыз!»
Юаталар мине: «Тиз кайтырбыз,
Бар да әйбәт булыр, улыбыз!»

Их сез, картлар, бер дә белмисез шул,
Әнкәемне килә күрәсем,
Тизрәк кайтып җитеп, чирләп яткан
Әнкәемнең хәлен беләсем!

Кем генә соң аңлар икән мине?
Әнкәй бәгърем өзелеп көткәндер.
Кайчан кайтып җитәр, дигәндер ул,
Иреннәре сусап кипкәндер.

Соңармыйммы? Дөнья бу башларга
Шундый авыр уйлар китерә.
Әйтче, авылым, әйтче, кара урман,
Нинди хәлләр әнкәм кичерә?

Әйтерсең лә уйны сизде бабам,
Үзе дә ул никтер ашкына!
Әй тотынды чаптырырга атны,
Тик юллар шул түгел таш кына.

Ашыктырып атны, бабам тоткан
Дилбегәне ныграк тартамын.
Терелерсең, сиңа бик кадерле
Якыннарың белән кайтамын!

Кинәт килеп чыккан шушы хәсрәт
Салды мине сагыш-моңнарга.
Юлда үткән сәгать-минутларын
Тиңләр идем хәтта елларга.

Ялварулы сабый тавышын да
Ишеткәндер Ходай, күрәсең.
Йолып алып үлем тырнагыннан,
Кешеләргә гомер бирәсең.

Еллар уза торды, без биш бала
Үстек, әнкәй, синең кочакта.
Кайчан әле сиңа утыз иде!
Синсез кала яздык ул чакта.

Нинди авыр чаклар кичердең бит!
Күпме күз яшьләре түгелгән!
Йокысыз төн, борчу, уйланулар
Сәламәтлек белән түләнгән.

Бирешмичә кырыс җилләренә,
Тормыш дәрьясында аккансың.
Балаларга күкрәк сөтең биреп,
Назларыңа төреп баккансың.

Исән-имин килеш син дә, әнкәй,
Тутырдың бит бүген сиксәнне.
И әнкәем, күрсәк иде синең
Туксан яшькә килеп җиткәнне!

Ул чагында биш яшьлек малайга
Каян килгән икән батырлык?
Әнкәйләргә булган мәхәббәт шул
Дөньяларны урап кайтырлык!

## САРЫ ЯФРАК ҖЫЙДЫМ, ӘНКӘЕМ!

Яфракларны җилләр уйнатканда,
Чал Иделдән тагын үттем мин.
Күзге җилләр алып килер сыман,
Туган йорттан сәлам көттем мин.

Җил очыртыр сары яфракларны
Әнкәй яшәп яткан җирләргә.
Торган җирләр күренмәсме диеп,
Шулчак мендем биек үрләргә.

Үргә менеп күпме карасам да,
Туган йортны аннан күрмәдем.
Бер истәлек булып калсын әле,
Сары яфрак җыйдым үрдә мин.

## РӘНҖЕТМИК ИЗГЕ ҖАННАРНЫ

Йоклый бала, йоклый тыныч кына,
Ана гына йоммый күзләрен.
Тоя микән сабый әнкәсенең
Уйлар диңгезендә йөзгәнен?

Татлы йокыларын калдырып, ул
Керфек какмый озын төннәрдә.
Эштән соң да ара тими аңа
Баш куярга ястык-мендәргә.

Ә без менә белеп бетермибез
Ниләр кичергәнен ананың,
Мең-мең төрле уйлар кочагында
Уздырганын кичен-таңнарын.

Кайчагында әйтеп куйгалыйбыз:
«Ник тудырдың безне бу җиргә?..»
Ут йоткандай ник соң ашыкмыйбыз
Үзләренең хәлен белергә?

Истә тотыйк тормыш йөген сөйрәү
Берсенә дә җиңел түгелен.
Авыр сүзләр белән рәнҗетмик без
Аналарның изге күңелен.

## РӘХМӘТ СИҢА БАРЫСЫ ӨЧЕН

Туңган чакларымда, әнкәй, мине
Мамык шәлләреңә төргәнсең.
Шифалары тимәс микән диеп,
Кайнар чәйләр ясап биргәнсең.

Хәлләремнең тойдым яхшырганын
Мәтрүшкәле куе чәеңнән.
Беркайчан да мине аермадың
Туган якның язы, җәеннән.

Син бәйләгән йомшак оекбашлар
Сакладылар салкын кышлардан.
Бәлки, шуңа очып йөримендер,
Калышмыйча җитез кошлардан.

Син пешергән татлы ризыклардан
Аерылмадым гомерем буена.
Күңелемдәге изге уем сиңа
Барып җитмәс кебек тоела.

Хисләремнең ихлас икәнлеген
Җырларымнан минем аңларсың.
Тик ул җырлар, әнкәй, беркайчан да
Ярты юлда бүленеп калмасын.

## ЮК, ҮКЕНМӘС ИДЕМ

Һәр балаңны фәрештәдәй күреп
Тудыргансың, әнкәй, дөньяга.
Игезәкләрең тугач, шатлыгың
Таралгандыр бөтен җиһанга.

Саклау өчен яман күзләрдән,
Ике чаршау корып куйгансыз.
Әбием белән безне чиратлап
Карагансыз, уяу булгансыз.

Уйламадым шушы тормышымда
Тотармын дип күпме имтихан.
Кырыс җилләреннән сакладылар
Безгә биргән хәер-фатихаң.

Сикәлтәле озын юллар аша
Без дә җиттек инде иллегә.
Яшәгәндә йөзгә кызыллыклар
Китермәдек, шөкер, әлегә.

Җырым минем, шигырьләрем, әнкәй,
Йөрәкләргә бәхет иңдерсә,
Юк, үкенмәс идем, бу гомерем
Кешеләргә шатлык китерсә.

## КАПЛЫЙ КЕБЕК ӘНКӘЙ КУЛЛАРЫ

Без, биш бала, табын әйләнәсен
Түгәрәкләп алып киткәнбез.
Кара чуеннарда мичтә пешкән
Ашларыннан авыз иткәнбез.

Һәркайсына әнкәй тигез итеп
Бүлеп бирә иде итен дә.
Кара ипиләрне мана-мана
Эчә идек куе сөтен дә.

«Уф алла»лар тартып үссәк тә без,
Кәнфит кенә ашап үсмәдек.
Кузгалагын татып үскәнгәдер,
Туган җирне ташлап китмәдек.

Йокымсырап ятам түшәгемдә,
Нинди матур айның нурлары.
Юрганымны өсләремә һаман
Яба кебек әнкәй куллары.

## ЕШРАК КАЙТЫЙК

Безгә гомер биргән әнкәйләрне
Искә алыйк һәрбер адымда.
Исән-саулыкларын белер өчен,
Ешрак кайтыйк алар янына.

Кошлар кебек очып кайтып килик,
Якынайтып ерак юлларны.
Авыр чакларында юатырга
Иңнәренә салыйк кулларны.

Күз нурларын, йөрәк парәләрен
Көтә алар һәрчак зарыгып.
Өннәрендә генә түгел, хәтта
Төшләрендә көтә сагынып.

Күчтәнәч тә, затлы бүләкләр дә
Өмет итмәс алар һаман да.
Аларга тик җылы сүзебез кирәк
Җан өшеткеч кырыс заманда.

Йөрәк тибешләрен тоеп яшик,
Ерак булса булсын аралар.
Якты өметләрен сүндермичә
Көтә безне газиз аналар.

## БЕР СЫЛУЫ ИТЕП

Зәй суының талгын дулкыннары,
Беләм, әнкәй, исеңә төшәдер.
Әрәмәләрендә ул чакларда
Бөрлегәннәр тулып пешкәндер.

Яшел чирәм үскән сукмак буйлап
Килгәнсеңдер аны җыярга.
Чишмәләрең көтеп алган сине
Татлы суы белән сыйларга.

Туган якның юмарт табигате,
Якын итеп, сине үз күргән.
Бөтен тирә-якны сокландырып,
Бер сылуы итеп үстергән.

## КҮЗ АЛДЫМА КИЛЕП БАСАСЫҢ

Менә кайтам, менә кайтам диеп,
Ай артыннан айлар үтәләр.
Чират тими, әнкәй, көн тудисә,
Кичектермәс эшләр көтәләр.

Һаваларга карыйм, күкне иңләп
Киек казлар очып барганда.
Күз алдыма килеп басасың син,
Кайт, дип, алар аваз салганда.

Сизеп торам, безнең якларгадыр
Аларның да очар юллары.
Сагыну хисләремне сиңа илтеп
Җиткererме икән моңнары?

Рәнҗү катыш ачуланма, әнкәй,
Бу юлы да озак көттердем.
Һаман шулай чит җирләрдә яшәп,
Күпме борчу сиңа китердем.

Аңлыйм, әнкәй, аңлыйм, җиңел түгел
Гомер итүләре сагынып.
Кавышу көнен көтеп алу өчен
Ходай бирсен безгә сабырлык.

## ӘНКӘМНЕҢ КҮЗЛӘРЕНДӘ

Болай да ярсу күңелнең
Тулып ташкан чаклары.

Кайтасымны белеп, әнкәм
Ачып куйган капканы.

Иңнәремнән кочып ала,
Өйгә килеп кергәндә.
Мөлдерәмә күз яшьләрен
Яшерми ул кемнән дә.

Туганнар, күрше-күләннәр
Ашыга яныбызга.
Имин тормыш, озын гомер
Телимен барыгызга.

Шулай диеп сәлам бирәм,
Шатлыгым чиктән ашкан.
Якын күреп, әбекәйләр
Сыйпыйлар минем баштан.

Уллары кебек яратып
Дәшәләр үзләренә.
Барсының уртак сагышы
Әнкәмнең күзләрендә.

## КАДЕРЕН БЕЛИК АНАЛАРНЫҢ

Басу юлларыннан күзең алмый,
Кайтырлар дип көтеп торасың.
Тик берсе дә кайтып күренмәгәч,
Башың иеп, уйга чумасың.

Көннәреңне шулай ялгыз калып
Үткәрәсең, әнкәй, тын гына.
...Ә без нишләп колак салмыйбыз соң
Аналарның йөрәк моңына?

Исән чакларында ник аларны
Һәр сулышта искә алмыйбыз?
Югалтуны алар җир йөзеннән
Китеп баргач кына аңлыйбыз.

## ҺАЙ, ГОМЕР ИТҮЛӘРЕ

Газиз әнкәм, талчыгуың
Сизелә карашыңда.
Тик һаман да мәш киләсең
Мал-туар арасында.

Ә шулай да җанга рәхәт,
Йомшак сүзләр телеңдә:
— Барчагызны да исән-сау
Күрәм, шөкер, бүген дә.

Оныкларымны назлыймчы,
Утыртып яннарыма.

Шулай дип, җылы сөт белән
Сыйлыйсың аларны да.

Иртәннән кичкә кадәр син
Аяк өстендә һаман.
Мең-мең төрле йорт эшләрен
Өстеңә өйгән заман.

Җиңел түгел шул кемгә дә,
Һай, тормыш итүләре.
Кызганыч ләкин гомернең
Ашыгып үтүләре...

## СУГЫШ БУЛМАС ИДЕ ДӨНЬЯДА

Ятим калдык, күпме югалттык без
Аталарны сугыш кырында.
Чечня җирендә кан коелганда,
Һич онытмыйк алар турында.

Онытырга түгел аналарның
Йөрәгеннән чыккан сүзләрен:
«Мин балама үзем ата булдым,
Ана булып багып үстердем».

«Сугыш» дигән коточыргыч сүзнең
Исеме корсын бөтен җиһанда.
Бар аналар күтәрелсә әгәр,
Сугыш булмас иде дөньяда!

## ИГЕЗӘКЛӘРЕҢ СИНЕ ТАШЛАМАС

Кыш айлары үткәч, кар-бураннар
Зәһәрләнеп улый алмаслар.
Җилләр ничек көчле иссәләр дә,
Бер туктамый, тынмый калмаслар.

Март шатлыгы кебек шатлык булмас,
Бар шатлыкны бергә җыйсаң да.
Язгы кичтә ике  игезәк малай
Аваз сала ошбу җиһанга.

Шунда, әнкәй, безне ак биләүгә
Биләгәндер йомшак кулларың.
Ике тамчы судай бер-берсенә
Охшаш булып үсте улларың.

Көйсез балаларны үстерүләр
Әллә җиңел булган дисеңме...
Җиргә тормыш биргән кояштан да
Өстен күрдек, әнкәй, без сине.

Безгә бишек җырын көйләгәндә,
Керфекләрең синең талгандыр.

Шуңа күрә, бәлки, йөзләреңә
Алҗыган төс иңеп калгандыр.

Кеп-кечкенә булып күренәсең
Ике игезәк улың янында.
Бертуктаусыз безнең хакта уйлап
Олыгаясың кебек тагын да.

Назларыңны тоеп, гомер буе
Иркәләнгән безнең җаныбыз.
Аз булды тик, кадерлебез, диеп,
Сине кочып алган чагыбыз.

Үпкәләмә, әнкәй, малайларың
Беркайчан да чәчрәп чыкмады.
Аңла ләкин: тыштан салкын булып,
Эчтән алар ялкын йотканны.

Барлык теләкләрең кабул килеп,
Гомер юлыбыз имин үтелгән.
Күпме аклык булса күңелебездә,
Барысы синең күкрәк сөтеннән.

Кан кардәшләр соңгы сыныкны да
Бер-берсеннән аерым ашамас.
Нинди хәлләр кичерсәң дә, әнкәй,
Игезәкләрең сине ташламас.

## ОЛЫ ҖАНЛЫ МАТУР КЕШЕ

Ул да кеше, кайгы, шатлыгы бар,
Тоташ бәйрәм түгел бу гомер.
Йөз кайгысын онытып, бер шатлыгын
Йөз кешегә сөйләп өлгерер.

Күңелеңдә инде сүнеп барган
Хисләреңне кабат уятыр.
Сагыш уты тулы йөрәгеңне
Җылы сүзе белән юатыр.

Авырып китсәң, дәваларга килер,
Хәлсезләргә куәт, көч бирер.
Кирәк икән әгәр, һичшиксез, ул
Таш өстендә гөлләр үстерер.

Һичбер вакыт күңеле төшмәс аның,
Шаян да ул, җитез, зирәк тә.
Иплэп кенә биргән киңәшләре
Шифа булып иңәр йөрәккә.

Үзе бер бәхет ул аның белән
Бергә утыруы гөрләшеп.
...Олы җанлы матур кеше яши,
Күңелләргә шатлык өләшеп.

## КОШЛАРДА ДА БАЛА ХӘСРӘТЕ

Очып китте кошның балалары,
Берьялгызы калды ояда.
Канатларын кагып бәргәләнә,
Белми үзен кая куярга.

И сызлана, изалана бәгърем,
Наныйларын көтә зарыгып.
Өмете инде тәмам киселгәндә,
Кайтып килерләр күк сагынып.

Әллә бала тавышы, әллә җилләр
Шыңшып куя тәрәз артында.
Һәр авазга колак сала ана,
Бар кайгысы бала хакында.

Түше белән сыйпый бичаракай
Сабыйлары яткан урынны.
Сөю белән шулай газапланган
Җан иясе тагын булырмы?..

Үзәкләрне өзгеч авыр хәлен
Кемнәр аңлар икән кошларның?
Аларда да бала хәсрәтенең
Чиксез булуына ышандым.

## АК ТЕЛӘКЛӘР ТЕЛӘП

Рәхмәт, әнкәй, сәфәр чыккан чакта
Хәер-фатихаңны биргәнгә.
Изге догаларың һәр адымда
Юлдаш булды дөнья гизгәндә.

Хәзер дә бит, юлга җыенганда,
Ак теләкләр теләп каласың.
Хәвефләрдән саклап, әйтерсең лә
Янәшәмнән атлап барасың.

Кыен вакытларда күңелем һәрчак
Сүзләреңне тыңлап юанган.
Язмыш берүк аермасын мине
Түр кесәмдә йөргән догаңнан.

Кайда гына булмыйм, бары сиңа
Багышлыймын йөрәк хисемне.
Уң як иңемдәге фәрештәгә
Тиңләп яшим, әнкәй, мин сине.

## СИН БИТ ҖИРНЕҢ ИҢ ЗУР ШАТЛЫГЫ

*Кадерле әниебез Рәсимә Нәбиулла кызына,*
*70 яше белән котлап*

Ямь-яшел җәй... Июль урталары...
Таң җилләре хәбәр китергән.
Изге хәбәр... Тыкрык-урамнарга
Таралган ул авыл читеннән.

Йодрык кадәр генә бер кыз бала
Аваз салган ошбу җиһанга.
Мондый шатлык булмас, бу тормышның
Бар шатлыгын бергә җыйсаң да.

Алгы көннәрдә дә кайгыларсыз
Булсын берүк гомер юллары.
Бишегеннән кояш яктысына
Үрелгәннәр нәни куллары.

Буйга җиткән... Без туасы йортка
Су юлыннан сукмак салынган.
Без биш бала якты җир йөзенә
Яралганбыз аның канынннан.

Ә шуларның икесе игезәкләр,
Юмарт та соң, ана, язларың!
Һәркайсына тигез бүләр өчен
Җитсен берүк җылың, назларың.

Сабыйлары хакына тормыш йөген
Сөйрәгән ул, төпкә җигелеп.
Үзенә дигән актык сыныгын да
Безгә бүлеп биргән иң элек.

Заманнары заманмыни аның,
Бөтен илне сугыш ялмаган.
Җан асрамакка хәтта кычыткан,
Черек бәрәңгесе калмаган.

Ул елларда күргән михнәтләре
Гомре буе китмәс күңеленнән,
Пәйгамбәрдәй изге җанлы булуы
Саклап калган безне үлемнән.

Хәтерендәдер язын авылыбызның
Күтәрәмгә калган атлары.
Чана тартып, ерак төбәкләргә
Симәнәгә барган чаклары.

Чабата һәм тула оек киеп,
Кич әле син бозлы суларны.
Искә төшереп, хәзер күз алдына
Китерәбез микән шуларны?

Йөрәкләрнең тоташ сыкрауларын
Тоябызмы икән менә без?
Якын туганнарның хәлләрен дә
Ана йөрәге аша беләбез.

Шул ук ана дәшә, гозерләнеп:
«Гыйбрәт алыгыз берүк үткәннән».
...Безнең генә түгел, җирнең дә бит
Күз карашы аңа текәлгән.

Исән генә була күр син, әнкәй,
Өйдә генә булсаң иде лә.
Син бит, әнкәй, безнең генә түгел,
Олы шатлыгы бит җирнең дә.

## ЯКТЫ ӨМЕТ БУЛЫП БАЛКЫДЫҢ

Юлыбызга маяк булып торды
Туры сүзең, аек акылың.
Кыен минутларда безнең өчен
Якты өмет булып балкыдың.

Һәрбер ата балаларын сөя,
Син дә, әткәй, безне сөйгәнсең.
— Кеше булып үсүләрен телим,
Безне ташламаслар, — дигәнсең.

Шул сүзләрең сабый чагыбыздан
Кереп калган күңел түренә.
Сине, әткәй, ничек яратмыйсың,
Безнең өчен син бит бер генә.

Авырлыклар килсә, һаман да бит
Ашыгабыз синең янына.
Киртәләрне җиңеп чыгар өчен,
Көч бирәсең безгә тагын да.

## КАДЕРЛӘРЕН БЕЛИК

Әнкәйләрнең бәхиллеген
Исән чакта алмасак,
Кирәклеген белмибез шул,
Авыр хәлгә калмасак.

Андый чакта, сорый-сорый,
Күзләреңнән яшь кипмәс.
Ничек кенә сорасаң да,
Ходай да ярдәм итмәс.

Шуңа күрә дөньялыкта
Белик лә кадерләрен.
Соңгы юлга озатсак та,
Онытмыйк каберләрен.

## ӘТКӘЙГӘ

Үзәк өзгеч, авыр ачлык елны

Син дөньяга аваз салгансың.
Бары җиде айлык сабый чактан
Ятим бала булып калгансың.

Үсмер чакта, яшьлек елларында
Сиздергәндер ачы ятимлек,
Зар булгансың ишетәсең килеп
Үгет-нәсихәтен әтиеңнең.

Язмышыңда язгач, малай чактан
Авыр йөкне җигелеп тарткансың.
Бәхет эзләп читтә йөрмәгәнсең,
Үз җиреңдә аны тапкансың.

Еллар арты еллар уза торды,
Биш баланың булдың әтисе.
Без дә хәзер ир уртасы булдык,
Синең яшькә иде җитәсе.

Нинди генә эшкә тотынсаң да,
Буйсындылар алтын кулларың.
Тырыш хезмәт, аек акыл белән
Уздырдың син гомер юлларын.

Авылның иң оста гармунчысы,
Менә дигән балта остасы.
Хезмәтең тик файда гына булды,
Әрәм булып, җилгә очмады.

Игелегең, күңел җылың итеп,
Хәтерләрдә мәңге саклырбыз.
Яхшылыкка, гаделлеккә кушкан
Ышанычың, әткәй, аклырбыз.

Җитмеш биш яшь тулды сиңа бүген,
Эшсез үтми әле көннәрең.
Ә кичләрен тальян моңы ага —
Гомерлеккә юлдаш һөнәрең.

Һәммәбез дә сиңа куанабыз,
Гел телибез бергә йөрергә.
Насыйп итсә иде безгә Ходай
Йөз яшеңне синең күрергә.

## ЯРЫЙ ӘЛЕ ӘТКӘЙ БУЛГАН

Ике авылның күгендә
Пар йолдызлар калыккан.
Бер-берләрен эзләп тапкан
Ярлар беркөн кавышкан.

Әй әнкәем, матур да син,
Бигрәк сабыр, тыйнаксың.
Аш-суга да, ай-һай, оста,
Өйдә — һәрчак кунак-сый.

Әткәй дә һич ким-хур түгел,
Буй-сыннары килешле.
Гармун тартып, бер көйләсә,
Сөймәс җирдән сөешле.

Әгәр, әнкәй, син булмасаң,
Әткәй өйләнмәс иде.
Өйләнсә дә, башка белән
Тормыш көйләнмәс иде.

Юләр чаклар узган инде,
Барлык яктан уйлыйсың.
Утыз яшьтә егет белгән
Ярны ничек сайлыйсың.

Син дә, әнкәй, бик бәхетле,
Яшәмәдең зар елап.
Ярый әле әткәй булган,
Гомерлеккә яр булып.

## ТИМӘ, КАРТЛЫК, БЕЗНЕҢ НИГЕЗГӘ

Әткәй-әнкәй, сез дә олыгаясыз.
Хөрмәтле йорт булды йортыгыз.
Үкенерлек итеп яшәлмәде,
Янып торсын һәрчак утыгыз.

Ачу тотмый гомер кичерәсез,
Татулыкка җаннар күнеккән.
Сезгә дошман булып йөргәннәр
Күптән инде китеп дөмеккән.

Саргаймас күк яшел чыршылар да,
Саргаясыз яшьләр түгепме?
Күпме еллар бергә яшәдегез,
Бергә картаясыз түгелме?

Кергән чакта атлап бусагадан
Нинди генә уйлар килми соң?
Бу картлык ник безнең нигезне
Уратып ла узып китми соң?

## МИН БИТ ӘЛЕ ЯТИМ ТҮГЕЛМЕН

Таш каладан тагын кайтып киләм,
Карыйсылар килми әйләнеп.
Уйламадым, гомер узар диеп,
Кала тормышына бәйләнеп.

Үч итепме яшьлек хыялыма,
Үз иткәндәй булдым каланы.
Юкка гына үз иткәнмен икән,
Сусап яшәр өчен саланы.

Күкрәк сөте аша бу сусаулар
Күчкән микән әллә анадан?
Аерылып тагын бер көн узмый,
Кайтасылар килә яңадан.

Әти-әни исән, гөнаһ булыр,
Кайтырга дип юлга чыкмасам.
Әремнәр дә мине әрләр сыман,
Бу юлы да кайта алмасам.

Аллаһыдан сорыйм иртәләрен,
Гомеркәйләр сезгә телимен.
Көзләремә кереп барганда да,
Мин бит әле ятим түгелмен.

## УҢДЫМ, ДИЕП, СЕЗДӘН, УЛЛАРЫМ

*Кадерле әтиебез Гомәр Җәгъфәр улына,*
*80 яше белән котлап*

Бер шатлыгы, бер кайгысы белән
Гомер уза, куллар талгандыр.
Уфтанмадың, тормыш авыр диеп,
Авырлыклар артта калгандыр.

Күңел инде узганнарны барлый,
Нинди кичерешләр кичелгән.
Биш баланы кеше итәр өчен,
Күпме сәламәтлек киселгән.

Янгын чыгып беркөн туган йортта,
Көл-күмергә кинәт калдык без.
Көзге байлыкларсыз, кыш кергәндә,
Кайгы-хәсрәтләргә талдык без.

Шундый кыен чакларда да, әткәй,
Белем йортларына өндәдең.
Авыр булыр сезсез, димәдең син,
Укытырга безне теләдең.

Без дә менә үсеп кеше булдык,
Барчабыз да төрле хезмәттә.
Тик вакытсыз китмә, калдырып ла,
Яшәтәсе килә хөрмәттә.

Ата кочагында ышыкланып,
Насыйп булды безгә үсәргә.
Ятимлекнең бар ачысын тоеп,
Туры килгән сиңа яшәргә.

Давылларда бөркет үз баласын
Яшерәдер канат астына.
Тынычлыгын җуйган чакта, җаным
Синең янга шулай ашкына.

Сиксән яшьтә кыю атларга да
Бирсен генә Ходай көчеңне.
Елларын да кызганмасын иде,
Сорап яшәр өчен хәлеңне.

Кайтып йөрик туган йортыбызга,
Сузылсыннар һәрчак кулларым.
Яшә, әткәй, татлы хисләр кичеп,
Уңдым, диеп, сездән, улларым.

## КАРАУЧЫСЫЗ КАЛГАН БАЛАЛАР

Кибетләргә чыгып керим дисәң,
Каласың ла кайчак югалып.
Хәер сорашып йөри сабыйлар,
Аяк асларында буталып.

Шомырт кебек кара бу күзләре
Ялт-йолт уйный, карый як-якка.
Өмет итеп нәни кулын суза,
Бирми калмассыңдыр садака.

Берәм-берәм учның төпләренә
Тамалар бит көмеш тәңкәләр.
Берсенә һич биреп өлгермисең,
Икенчесе килеп төрткәләр.

Мөлдерәгән күз карашын текәп,
Кемнәргәдер карап торадыр.
Күрмәмешкә салыша кайсыдыр,
Читләтеп лә узып барадыр.

Кемнәр мәҗбүр итә аларны соң,
Сукбайлыкта шулай йөрергә?
Урам тормышларын үз итеп лә,
Бер мәгънәсез гомер сөрергә?

Киләчәккә нинди алмаш калыр,
Ил тоткасы булыр кемнәрдә?
Ышанып ла тапшырырбыз икән
Тормыш дилбегәсен кемнәргә?

Нишләдек соң, нәрсә булды безгә?
Ник кешеләр шулай үзгәрде?
Кем гаепле, әллә заманамы
Шундый чиккә безне җиткерде?

Сугыштан соң авыр елларда да
Мондый хәлгә калмаган алар.
Ата-ана исән-имин килеш,
Караучысыз калган балалар.

## ТЫНМА, КҮҢЕЛ

Таңнан хәбәр биреп, көләч кояш
Күтәрелә илем күгенә.
Әле кайчан гына изрәп яткан
Бар тирә-як нурга күмелә.

Мәхәббәт тә, кояш нурларыдай,
Якты хисләр миндә уята.
Йокымсырап барган йөрәгемдә
Җыр кузгата, давыл уйната.

Тынма, күңел, сөю уты синдә
Сүнми янар өчен кабынсын.
Күкрәгемдә яшьлек кайнарлыгы
Ахыргача саклап калынсын.

## КОЯШ БУЛЫП БАЛКЫ

Сагышларга салып, мине нигә
Сөю хисләренә урадың?
Сүнмәс ялкыннарга төреп, үзең
Кай якларга китеп югалдың?

Шуннан бирле тынгы белмәс җаным
Урын таба алмый үзенә.
Күңелемә кабат яз китер дә
Кояш булып балкы йөземдә.

## КҮҢЕЛЛӘРГӘ ЯЗЛАР КИТЕРӘ

Мәхәббәттән күеп көлләр булды,
Тик сүнмәде йөрәк, дөрләде.
Чөнки Иштирәге, Керәч-тавы
Назларына сөеп урады.

Дәрьяларга сыймас йөрәк моңы
Бәргәләнми, көйли тын гына:
Сөю җырлый! Ә җырлары аның
Хәтсез хәлләр булып,
Тау битләрен сыйпап, талгын гына
Офыкларга барып орына.

Юк, югалмый! Йөрәкләргә сеңеп,
Килер буыннарга иңдерә.
Хисләренә җилләр тидермичә,
Күңелләргә язлар китерә.

Мең сорауга җавап эзли шагыйрь,
Тынгы белми аның күңеле.
Әллә бер сораудан бер сорауга
Бара микән аның гомере?

Сагышларын басып яшәр өчен

Ходай биргән аңа сабырлык.
Мәхәббәттә янып күккә иңү —
Үзе җиңү, үзе батырлык.

## АДАШТЫРМАС МИНЕ ЮЛЛАРЫМ

Бөтенесен онытып, әйтерсең лә
Бар табигать сиңа табынган;
Барыр юлларыңны яктыртырга
Күпме йолдыз балкып кабынган!

Ай да әнә сиңа карап тора,
Күпме сагыш, моң-зар аңарда.
Язган аңа шулай гомер буе
Берьялгызы калып янарга.

Йолдызлар күп... Әмма минем өчен
Иң яктысы бары син аның.
Син сүнмичә янсаң, мәхәббәттә
Адаштырмас мине юлларым.

## КӨЗГЕ УЙЛАНУ

Кай арада җәйләр үтеп киткән,
Саргылт төскә керде аланнар.
Инде көз җитүен хәбәр итеп,
Яфракларын коя чаганнар.

Шаян җилләр яфрак түшәп киткән
Сукмакларга теким күземне.
Җил очырган ялгыз яфраклардай
Хис итәмен шунда үземне.

Урман буйлап бергә узган чаклар
Күз алдыма килә яңадан.
Аерыласы килми бу күңелнең
Яшьлеккә тиң җәйге таңнардан.

Ул таңнарның якты хатирәсе
Күчә бара, ахры, җаннарга.
Кышлар аша кичеп, йөрәк безне
Әйдәп бара килер язларга.

## ӘЛЛӘ НИШЛӘДЕМ

Күңелем тулы сөю... Шуңадырмы
Бу көннәрдә әллә нишләдем...
Шигырь язам... Дуслар йөрәгенә
Барып җитәр микән хисләрем?

Бар дөньямны онытып газапланам,
Каләм алдым исә кулыма.
Тойгыларым, уй һәм кичерешләрем

Сыяр микән шигырь юлына?

Язам, бозам, сызам... Үз урынына
Куя алырмынмы ноктаны?
Сөю хисем җырга әйләнерме,
Дус-ишләрем аны отармы?

## СИНЕ ЮАТЫРДАЙ СҮЗЛӘР ЭЗЛИМ

Әй укучым, әгәр белсәм икән
Йөрәгеңне ниләр телгәнен,
Нинди авыр уйлар кочагында
Үткәнлеген көнең, төннәрең.

Сине юатырдай сүзләр эзләп
Гизәр идем ерак юлларны.
Шул сүзләрдән генә тукыр идем
Сиңа атап язган җырларны.

## БЕРГӘ БУЛМАСАК ТА

Сагыныплар мине яшәсен дип,
Яннарымда гына калмадың.
Тормыш юлын бергә узар өчен
Гомерлек яр була алмадың.

Әйтерсең лә син яшәгән якка
Очып китте кошлар төркеме.
Синсез генә шулай бу гомернең
Үтеп китте тагын бер көне.

Сагышларны үлчәүләргә салып
Үлчәп булса иде аларны.
Башкаема кертмим сагышлардан
Сыгылырмын дигән уйларны.

Тоеп яшә тормыш шатлыкларын,
Мәңге якты булсын көннәрең.
Яшен-күкрәүләрсез үтеп китсен
Болыт каплап алган төннәрең.

Барыр юлыбызга шатлыгы да,
Кайгысы да тау-тау өелгән.
Бергә булмасак та, шушы җирдә
Синең яшәвеңә сөенәм.

## СЕР СЫНАТМАС ГҮЗӘЛ ЗАТЛАРГА

Яши әле авыл бирешмичә,
Тынып тормый аның җырлары.
Сер сынатмас апа-сеңелләрне
Үзенә дәшә ферма юллары.

Татлы йокы белән исәпләшмәү
Күптән кергән инде гадәткә:
Савымчылар эшкә кузгалалар
Таң беленеп килгән сәгатьтә.

Күнегелгән, резин итекләрнең
Төшкәне юк хәтта аяктан.
Сыкранмыйлар, әрсез зәһәр җилләр
Дулап иссәләр дә һәр яктан.

Сулышлары белән малкайларын
Җылыталар андый чагында.
Ә кешеләр шуны уйлый микән,
Утырганда сыйлы табында?

Бер уйласаң, алар ил өчен дип,
Күпме генә газап чикмәгән?
Юк, барыбер, җиңел бәхет эзләп,
Туган җирен ташлап китмәгән.

Аһ-зарларсыз яшәп кара шулай
Бүгенгедәй кырыс заманда.
Бу тормышны сөеп көн иткәнгә,
Көр күңелле алар һаман да.

Алардагы шушы рухи көчне
Гомер буе кирәк сакларга.
Ап-ак сөттәй ак бәхетләр телик
Фәрештәдәй асыл затларга!

## ГОМЕРЛЕККӘ ШУЛАЙ КАЛЫГЫЗ

Әллә күзләр җиткән — баш очыннан
Каңгылдашып кошлар үттеләр.
Соңгы авызлары ник шулкадәр
Сагышларга салып киттеләр?

Сыгылып ла төшкән ботакларда
Алсуланып пешкән баланнар.
Ялгыз итмик басу-кырларны дип,
Иңләп йөри атлар-колыннар.

Сары юрган кебек, сары яфрак
Сырып алган урман буйларын.
Күзге муллык белән күпме парлар
Үткәрәдер никах туйларын.

Күзләр бүләк иткән бәхет белән
Башлансын ла гомер юлыгыз!
Иң бәхетле парлар сез икән бит,
Гомерлеккә шулай калыгыз.

## КИЕК КАЗ ЮЛЫ БУЙЛАП

Барыр юлыбызны нурга күмә
Кич кабынган сихри йолдызлар.
Яктылыгын күреп күгебезнең,
Бер көнләшсен әле ялгызлар.

Тәрәзәмне ачып айлы төндә,
Һаваларга карап уйланам.
Куанычым ташый, ярый әле
Юлларыбыз аерым булмаган.

Киек Каз Юллары буйлап шулай
Уй-хисләрем сиңа сузыла.
Килер көннәрдә дә күзләребез
Текәлсеннәр бер үк йолдызга.

## ТОЛ ХАТЫНГА

Нигә әле шулай тынып калдың,
Башкаеңны салып мендәргә?
Алда әле кылыр эшләрең бар,
Ялгызлыкны кирәк җиңәргә.

Көн-төн уйлап артык бетеренмә,
Тормыш җиңел түгел болай да.
Сабырлыгың җуеп, һаман саен
Толлар зарын тыңлап моңайма.

Җирдә бөтенләйгә рәнҗетелгән
Кеше итеп тойма үзеңне.
Насыйп ярың эзләп табар да бер
Сөртер әле яшьле күзеңне.

## ПАРСЫЗЛАРНЫҢ ХӘЛЕН КЕМ АҢЛАР...

Бу тормышта пар булырдай ярлар
Нигә шулай соңлап табыла...
Дөрли-дөрли сөю ялкынында
Кереп барам гомер язына...

Язларымда, бәлки, очрарсың да
Килеп чыгарсың күк каршыма.
Түземлеген җуйган йөрәк һаман
Сине күрер өчен ашкына.

Хисләремә җилләр тидермичә
Көтәм сине күпме заманнар.
Өметләрен өзми янып йөргән
Парсызларның хәлен кем аңлар?

## БИК КҮП АЛАР

Күпме әле җирдә яр тапмыйча

Зар булганнар, газап чиккәннәр.
Мәхәббәтен көтеп арыганнар,
Ялгызлыкта гомер иткәннәр.

Бик күп әле җирдә пар булып та,
Бу тормышта газап чиккәннәр,
Мәхәббәт дип уйлап алданганнар —
Бер куышта гомер иткәннәр.

## КАДЕРЛӘРЕН БЕЛИК АЛАРНЫҢ

Хатын-кыз ул — изге җан иясе,
Нәсел җебен дәвам итүче.
Бер-берсенә ялгап, буыннарны
Килер заманнарга илтүче.

Тормыш иткән ирләр гомер буе
Шулар акылына табынган.
Шулар саклый безне афәтләрдән,
Йолып ала җилдән, давылдан.

Башыбызга бер-бер кайгы төшсә,
Шулар сизә аны иң алдан.
Кешелек бит үзе шул затларның
Вөждан-намусына инанган.

Юкка әйтмәгәннәр, оҗмах, диеп,
Аналарның аяк астында.
Хатын-кызлар кичкән газапларның
Аңлыйбызмы икән барсын да?

Һәркайсының әле кадерен белеп
Җиткермибез бугай һаман да.
Гомер юлыбызда тугры булып
Яши алсак иде аларга.

## ТОЛЫМНАРГА ТИМӘГЕЗ!

Толым-толым чәчкәйләрең
Көн дә сүтеп үрәсең.
Әсир итте толымнарың,
Төшләремә керәсең.

Ак яулыклы әбиләр дә
Яшьлекләрен сагынсын.
Озын чәчле гүзәлләргә
Фәрештәләр табынсын.

Нечкә билле зифа буйга
Күз тидерә күрмәгез.
Садәлеген саклап йөргән
Толымнарга тимәгез!

## ШУЛ УК ТОЛЫМНАР!

Гашыйк итеп кайнар яшьлегемдә,
Очрадың син минем юлымда.
Ак тасмадан үргән толымыңа
Гашыйк булдым мин ул чагында.

Янып торган сусыл иреннәрең,
Көлеп торган назлы күзләрең,
Ул гаҗәеп озын керфекләрең,
Фәрештәдәй нурлы йөзләрең!

Тик нигәдер бар нәрсәдән өстен
Күренделәр миңа толымнар.
Күз алдымда тора ул толымнар,
Узсалар да инде күп еллар.

## ЧИБӘРЛӘРГӘ ГАШЫЙК БУЛДЫМ, ДИЕП...

Икебез дә бер үк җирдә туып,
Бергә укып, бергә торганбыз.
Сүз куешкан кебек, икебез дә
Бер матурга гашыйк булганбыз.

Юк, беркем дә әле кире какмый
Безнең якын дуслар икәнне.
Йөрәкләрдә ләкин көнләү хисе
Бер уяныр, соңмы, иртәме.

Әллә каян белеп-сизеп торам:
Бер үк утта дөрләп янабыз.
Бер үк утка карап җылынсак та,
Салкыная безнең арабыз.

Чибәрләргә гашыйк булдык, диеп,
Бозыйкмыни дуслык йоласын?
Кайсыбызны сөяр, бу турыда
Мәгъшукабыз ныграк уйлансын.

## КОШЛАР ТЕЛЕН БЕЛМӘСӘМ ДӘ

Оеп утырганда җәйнең
Ягымлы кояшына,
Күзем төште бакчадагы
Сыерчык оясына.

Каурыйларын төзәткәләп
Бизәнә асыл кошчык.
Аңа якын гына җирдә
Чыркылдый әрсез чыпчык.

Бу оядан чыкмыйбыз дип
Тарткалашкан сәгате.
Каян алган чыпчык халкы

Шундый яман гадәтне?

Кошлар телен белмәсәм дә,
Сүз башламый түзмәдем:
— Нишләп әле әзер йортка
Төшә һаман күзләрең?

Вакыттыр бит инде сиңа
Шул нәфесеңне тыярга.
Тыныч кына көн итәргә
Үзең корганояда.

## КАЛДЫР МИНЕ ТЫНЫЧЛЫКТА

Башкаларга күптән бүлеп биргән
Назларыңның тоймыйм җылысын.
Вакланганын түгел, күңелем минем
Мәхәббәтнең тели олысын.

Юк, җыенма мине юатырга,
Гөлдәй сулыр, димә, кайгыдан.
Калдыра күр берүк тынычлыкта,
Юлларыбыз инде аерылган.

Килә минем, килә тормышымны
Үз дигәнем белән корасым.
Аны көтеп алыйм дигән чакта
Янымда син пәйда буласың.

Тынычлыкта калдыр, сорыйм синнән,
Каршы чыкма минем юлыма.
Язмышыңны күптән тапшыргансың
Икенче бер кеше кулына.

## АЛДАНМАСЫН, ДУСЛАР, КҮҢЕЛЕГЕЗ

Гөлзәбирәм үксеп елап калды,
Марусяга киттем ияреп.
Бер күрүдә әсир итте мине,
Гомер буе туймый сөярлек.

Яшәп калыйм, татып калыйм, дидем,
Интим бәхетләрнең тойгысын.
Дәртле марҗа кочагына кереп,
Кайгыларның онытыйм соңгысын.

Үзенә шулай караттыра торган
Бер-бер сере бармы марҗаның?
Бер таратып салса толымнарын,
Әллә нишләп китә җаннарың.

Төпсез күлдәй зәңгәр күзләренә
Суырып алды бөтен уемны.
Әйтерсең ул миңа бу дөньяның

Алиһәсе булып тоелды.

Йомшак күкрәгендә иркәләнеп
Узар кебек иде таңнарым.
Тик мин аның бары тере курчак
Булганлыгын соңрак аңладым.

Гомер үтте... Азмы киртәләргә
Очрадым мин тормыш юлымда.
Ул бит тиеш иде авыр чакта
Миңа һәрчак терәк булырга.

Кайгыларны тигез бүлешергә,
Һәр җырымны уртак итәргә.
Халкым йолаларын мыскыллаган
Бәндәләрне читләп үтәргә.

Тыштан гына хуплап йөргән икән
Теләк-уйларымның барсын да.
Юрауларым, матур хыялларым
Калды аның аяк астында.

Назга саран, холкы салмак, диеп,
Чит итмә син татар кызларын.
Сайла тыйнак, сабыр шул кызларның
Тормышыңа юлдаш булганын.

Яшь чагында шулай минем кебек
Алданмасын, дуслар, күңелегез.
Олыгайгач, чибәр марҗаларга
Беребез дә кирәк түгелбез.

## АКЫЛЛАРЫҢНЫ ҖУЙМА

Тормыш шаулап ага бүген,
Бигрәк назлы җилләрең.
Сөлек кебек кызлар үсә,
Танымассың үзләрен.

Нәфис, йомшак тавышлары,
Сихерле карашлары.
Үзе генә ни тора соң
Чәч үреп-тарашлары.

Кемнәр генә гашыйк булмас
Мондый сылу кызларга?!
Кемнәргәдер күз тидерми
Насыйп булсын назларга.

Яшьлек бит ул, яшь чагында
Сөйгән ярлар күп була.
Тормышта яр сайлаганда
Гомерлеккә дип сайла.

Иң нәфис гөл ул — мәхәббәт,

Карап тор шиңдермичә.
Гөлне саклагандай сакла,
Җил-яңгыр тидермичә.

Бер минутлык мизгелләре
Өзсә дә бу үзәкне,
Ялгышулар гомерлеккә
Яралый бит йөрәкне.

Фахишәлек — сазлык кебек,
Керүләргә юл куйма.
Чыгулары авыр булыр,
Акылларыңны җуйма.

## ӘЛЕ ХӘЗЕР ГЕНӘ АҢЛАДЫМ

Сызланмыйча күңелең ничек түзсен,
Хушлашулар искә төшкәндә.
Аерып кара ике чәчәкне син,
Берсен берсе назлап үскәндә.

Юлларыбыз нишләп адашкандыр,
Сәбәпләрен инде эзләмә.
Яшерен сагыш, татлы-кайнар өмет
Уртак юлдаш иде безгә дә.

Без яраткан шомырт куаклары
Хәзер дә бит ап-ак чәчәктә.
Янып сөю ләззәтеннән бизеп
Булмый икән, күпме яшәп тә.

Җылылыгын, рәхәтлеген тоеп
Гомер итәм синең күңелнең.
Сине иң илаһи затларга да
Алыштырыр кеше түгелмен.

Бер-бер авырлыкка тарыганда,
Өмет белән сиңа текәләм.
Елмаюың шифа булып иңә,
Кайгыларны җиңел үткәрәм.

Бары тик син булган җирдә генә
Ак бәхетләр керә төшемә.
Шул бәхетне ихлас бүләк итеп
Бирүчеләр кирәк кешегә.

Әй бу еллар, үткән гомеркәйләр,
Узган юлда калган ялгышлар.
Башкаларга бары гыйбрәт кенә
Булсын иде безнең язмышлар.

## КИЧЕРӘ ҺӘМ СӨЯ БЕЛСЕННӘР

Ятлар белән гыйшык тотсагыз да,

Чамасыннан артык узмагыз.
Ачу, нәфрәт саклап кешеләргә,
Дөньяларны артык кумагыз.

Үпкәләрне озак сакламагыз,
Хаталарны таный белегез.
Ачуларны читкә таратмыйча
Хәл итегез барсын үзегез.

Ятимлекне күреп үсмәсеннәр
Бер гөнаһсыз җирдә сабыйлар.
Татлы мизгелләрдә уяулыкны
Югалтмасын иде абзыйлар.

Ханымнар да күркәм, түзем булсын,
Нәфислеген алар җуймасын.
Адашып ла ялгыш бу дөньяда,
Ямьсез юлдан китеп бармасын.

Кылган ялгышларга үкенеп лә
Сыкранмасын безнең күңелләр.
Кичерә һәм сөя белгәннәргә
Ходай бирсен озын гомерләр!

## ХИСЛӘРЕҢНЕ ЙӨГӘНЛӘ

Язгы кояшның нурлары
Җир өсләрен балкыта.
Йөрәкләрдә мәхәббәтнең
Хисләре баш калкыта.

Хисләр дә, кичерешләр дә,
Шул ук, бер үк йөрәктә.
Их, йозакка бикләп кенә
Тотсаң иде кирәктә.

Ташкын булып хисләреңнең
Кузгалганын күрәсең.
Тик ул хисләр акылыңнан
Өстен була күрмәсен!

## ТЫЙНАКСЫЗЛЫК ҺИЧ КИЛЕШМИ

Яшьле күзләреңне миңа
Ник тутырып карыйсың?
Сөям, дигән сүзләр белән
Нигә мине алдыйсың?

Тыштан гына күз яшь түгеп,
Эчтән көлеп йөрисең.
Кемгә гашыйк булганыңны
Үзең дә бит белмисең.

Күбәләктәй гөлдән гөлгә

Кунасың һаман шулай.
Сиңа инде чәчәкләр дә
Ятсынып карый бугай.

Тыйнаксызлык һич килешми
Безнең татар кызына.
Азгын затларга ияреп,
Мәхәббәттә узынма.

## БЕЛМИ АЛАР...

Бу тормышта шундый бер күренешкә
Бармы синең шаһит булганың?
Кайберәүләр сизми үз дигәне
Янында ук басып торганын.

Гомере буе йөри чибәрләрне
Читтән эзләп, читтән күзәтеп.
Белми алар: уйламыйча кылган
Ялгышларны булмый төзәтеп.

Матур чәчәкләргә үрелгәндә,
Мул түгәләр йөрәк хисләрен.
Күрмиләрдер, ахры, ул гөлләргә
Сырланнар да сарылып үскәнен.

## НИШЛИМ СОҢ, ДУСЛАР?

Ярларга сугылып,
Дулкыннар ургыла.
Су өстен каралтып,
Болытлар агыла.

Минем дә язмышым
Шуларга охшаган.
Яшьлегем хыялы
Тормышка ашмаган.

Ярымны югалттым,
Бәлки, ул гомергә.
Яшәрмәс күңелем,
Сүрелде мәңгегә.

Җаннарым сусаган,
Йөримен тилмереп.
Нигә син дустыңны
Яшисең тилмертеп?

Яшимен еракта,
Сагындым, талларым.
Адаштым тормышта,
Нишлим соң, дусларым?

## СИНЕҢ ЭЗЛӘРЕҢНӘН

Тормышымда насыйп булды тагын
Синең эзләреңнән үтәргә.
Син яраткан салкын чишмәләрнең
Суларыннан авыз итәргә.

Юл читендә үскән имәннәрдән
Сораштым мин синең хакыңда.
Үткән еллар кереп качкан гүя
Сарсаз тауларының артына.

Кайтавазлар булып көмеш тавышың
Ишетелә яшел болында.
Истәлекләр калган кайчандыр без
Бөрлегәннәр җыйган урында.

Кая китте, кая югалды соң
Бер гөнаһсыз чая балачак?..
Ул, мөгаен, шулай гомер бакый
Безнең алдан атлап барачак.

## САГЫНЫРСЫҢ КЕБЕК

Мин бит синнән күпне өмет итмим,
Карашларың белән иркәлә.
Яннарыңнан узып киткән чакта
Күзләрем гел сиңа текәлә.

Була кайчак шундый минутларым —
Еракларга килә китәсем.
Тик йөрәкне булмый буйсындырып,
Ничек аңа хыянәт итәсең.

Китеп барсам, сагынырсың кебек,
Юксынырсың кебек тоела.
Күз яшеңне түгеп ялгыз яшәү
Ансатмыни гомер буена?

Сине шулай янып сөюемнең
Серен аңлый алмыйм һаман да.
Сине уйлыйм, гөлләр керфегеннән
Үләннәргә чыклар тамганда.

## КӨТ СИН, ИРКӘМ

Китеп бардым басу юлы буйлап
Авыр моңга чумып, борлыгып.
Шушы кадәр кыен булмас иде,
Ник карадым икән борылып.

Әткәм, әнкәм, газиз туганнарым
Басып калды авыл башында.
Кире кайтып, күкрәгемә кат-кат

Кысып алдым гүя барсын да.

Алар белән бергә  кырларым да
Дәште кебек озатып калганда:
— Сагынырбыз сине, юксынырбыз,
Бергә чакны искә алганда.

Сау булыгыз, туган якларымның
Тал-тирәкле инеш-күлләре.
Күл буенда үскән сөйгәнемнең
Яшьлегемә сердәш гөлләре.

Сау бул, иркәм! Оныта алмам сине,
Яшәсәм дә кайсы җирләрдә.
Сүрелерлек түгел, сиңа булган
Мәхәббәтем дөрли тирәндә.

Хисләребез һаман уртак янсын,
Кырыслыгын тоймыйк җилләрнең.
Күккә кара, син күрерсең анда
Ак болытлар йөзеп килгәнен.

Шул болытлар миннән сәлам илтер
Айлы кичтә, моңсу таңнарда.
Кайда булсалар да, ике йөрәк
Берсен берсе тиеш аңларга.

Нишлим, иркәм, бик-бик теләсәм дә
Яннарыңда синең калырга,
Китеп барам Казан каласына
Инә белән кое казырга.

Тынгы белмәс яшьлек тели шулай
Төшенергә тормыш серенә,
«Белем йорты» дигән изге йортның
Ишекләрен шакып керергә.

Нинди кыенлыклар кичерсәм дә,
Юк, буйсынмам язмыш иркенә.
Ирешмичә калмам теләгемә,
Көт син мине, иркәм, көт кенә.

## ТҮЗӘ АЛЫР МИКӘН?

Сагыш тулы йөрәгемне алып,
Китеп барам тагын еракка.
Өлешемә тигән нинди язмыш
Тарта икән мине ул якка?

Тирән-тирән упкыннарны кичеп,
Үрмәлимен текә тауларга.
Таш кыялар хәтта эрер кебек,
Кайнар күз яшьләрем тамганда.

Таулар арасыннан аккан сулар

Ишеттерә микән сүземне?
Шул суларның ярсу дулкынында
Тирбәлгәндәй тоям үземне.

Сине уйлап, агымсуда түгел,
Хыял диңгезендә йөзәмен.
Сагышларга, белмим, ахыргача
Түзә алыр микән йөрәгем?

## ЮЛЫҢ ҮТСӘ КИҢ ЕЛГАЛАР АША

Сөйгәнемне эзләп табармын, дип,
Кайсы сукмаклардан узасың?
Нинди чәчәкләргә юлыгасың да
Нинди матур көйләр сузасың?

Юлың үтсә киң елгалар аша,
Кичүләрнең сайла саерагын.
Үзең әле аңлап бетермәгән
Серләр белән тулы һәр ягың.

Ымсындырган энҗе-мәрҗәннәрнең
Ашыгып үрелә күрмә барсына.
Мәхәббәтең үзе эзләп табар,
Үзе килеп чыгар каршыңа.

Гыйшык уты булып янган хисең
Сүрелмәсен һичбер минутта.
Тугрылыклы булып калыр өчен
Син үзең дә чынык шул утта.

## БӘХЕТЛЕ БУЛАЛМАССЫҢ!

Ташлап китсә, бигрәк авыр,
Яшьли сөйгән ярларың.
Сагынуларга дәва юктыр,
Нишләтим дөньяларын?

Үзең белән алып киттең
Бөтен җиһанның нурын.
Хәсрәтләргә салып мине
Калдырдың бит, күз нурым.

Аһ-зарларга юл куймаска
Тырышып карасам да,
Булмый икән, чәчләремне
Йомшартып тарасам да.

Миннән артык яхшыларны
Барыбер табалмассың.
Чит-ятларны үз итсәң дә,
Бәхетле булалмассың!

## СӨЙГӘН ЯРЫҢ ТАШЛАГАЧ

Узган чакта яннарыңнан
Карадың бит текәлеп.
Карашларың иркәләде,
Йөрәгемне телгәләп.

Әкрен генә сүзләр каттым,
Белер өчен серләрен:
Күзләреңнән күреп алдым
Миңа булган хисләрең.

Сөйсәң дә син, чит-ятларның
Назларына бирелдең.
Күңел тынычлыгын җуеп,
Сагышларга күмелдең.

Утлы тимер мичләрендә
Янамын күк тоела.
Нигә шулай җәфалыйсың,
Күз яшьләрем коела.

Даруларның файдасы юк,
Җаның тыныч булмагач.
Бу дөньяның бер гаме юк,
Сөйгән ярың ташлагач...

## БЕР КҮРЕШҮ ӨЧЕН БУЛСА ДА

Еракларга китеп бардың, дустым,
Берүземне ялгыз калдырып.
Яшим менә хәзер сине көтеп,
Парсыз калган коштай каңгырып.

Син дә кайталмыйсың, мин үзем дә
Бара алмыйм синең янына.
Калдымыни бергә вакытларны
Сагынып кына искә алырга?

Җаен таба заман бер-берсеннән
Ерагайтыр өчен кешене.
Ил өстенә килгән кара афәт
Нинди хәлгә безне төшерде!

Эзләп тапкан хәләл акчаңны да,
Күрсәң, бары төштә күрерсең.
Очар кошлар гына бәхетледер,
Эзләп таба алар бер-берсен.

Ник рас килми... таңнар һәр көн саен
Очрашулар юрап туса да.
Яннарыңа барып кайтыр идем
Бер күрешер өчен булса да.

## СИНЕ КӨТЕП

Көт, килермен, диден аерылганда,
Ник тормадың әйткән сүзеңдә?
Сине көтеп таңнар аттырганда,
Йокы керми минем күземә.

Карашымны алмый тәрәзәдән
Уйлар диңгезенә күмеләм.
Йомшак-назлы сулышыңны тойган
Минутларым чыкмый күңелдән.

Өннәремдә Сак белән Сок кебек,
Ә төшемдә һаман гел бергә.
Сорыйм синнән, Ходам, язмышыбыз
Уртак булсын иде гомергә.

Йөрәк яраларым әрнегәндә,
Сине генә уйлап юанам.
Җирне ямьләндереп бу дөньяда
Синең яшәвеңә куанам.

Уйларымда тормыш юлларыбыз
Бер-берсенә килеп үрелә.
«Көт, килермен» дигән сүзең һаман
Яңгырап тора колак төбемдә.

## СОҢАРГАН МӘХӘББӘТ

Сөюемне көтеп, берьялгызым
Ел артыннан еллар озаттым.
Кайчан да бер очрашырбыз, диеп,
Үз-үземне күпме юаттым?

Шундый өмет белән яши торгач,
Сизелмәгән гомер узганы.
Сизелмәгән вакыт дигәненең
Маңгайларга сырлар сызганы.

Аерым яшәсәк тә, күңелләрдә
Сүрелмәгән яшьлек сулышы.
Соңга калып килгән мәхәббәтнең
Күңелләрдә яши җылысы.

## СИНЕҢ ЯЗЛАРЫҢА СУСАДЫМ

Синең язларыңа сусадым мин,
Ямансулап үтә көннәрем.
Яннарымда булсаң, шушы кадәр
Сулкылдамас иде йөрәгем.

Синең язларыңа сусадым мин,
Сагышлардан йөрим тинтерәп.

Талпынамын очар кошлар кебек,
Тормышыма минем син кирәк.

Синең язларыңа сусадым мин,
Гомерлеккә калдың хәтердә.
Сиңа гына дигән сүзләремне,
Беркемгә дә базмыйм әйтергә.

Минем җаным синең язларыңа,
Йомшак назларыңа сусаган.
Миңа беркайчан да көзләр түгел,
Язлар бирәсеңә ышанам.

## НИК ОЧРАДЫҢ МИНЕМ ЮЛЫМДА?

Тәүге тапкыр сине күрү белән,
Әллә нишләп китте күңелем.
Тойдым гүя шунда бер минут та
Синсез яшәү мөмкин түгелен.

Тынгылыгын җуйсын, диден мәллә,
Ник очрадың, әйтче, юлымда?
Сизмичә дә калдым, әйтерсең лә
Әверелдем синең колыңа.

Нигә шулай әсир иттең мине,
Әйләндереп башым-күземне?
Төнге йокыларым качырдың да
Оныттырдың әйтер сүземне.

Күпме еллар узган, ә каршымда
Торасың күк һаман елмаеп.
Сагынамын, димә, төшләреңә
Бер керермен әле, моңаеп.

## МӘХӘББӘТСЕЗ МӨМКИН ТҮГЕЛ

Очраттым дип мәхәббәтне,
Йөргәнмен шул табынып,
Сизенсәң дә, йөрәккәем,
Киткәнсең бит кабынып.

Сөйгәнеңә сөюеңне
Йөрсәң дә бит сиздерми,
Нинди сихри көчләр соң ул,
Йөрткән икән биздерми?

Бизенмәс тә берчак бизәр,
Хисләреңне яшерсәң.
Уйланырсың, ул чакларны
Исләреңә төшерсәң.

Төшерсәң дә, битәрләмә
Кыюсыз ул егетне.

Айлар түгел, еллар узды
Көтеп ул мәхәббәтне.

Шулай итеп бу гомернең
Гүзәл чаклары үткән.
Һаман нидер көтә-көтә,
Яшәүләр дәвам иткән.

Белмибез шул, кем белә соң
Алданиләр буласын?
Белсәк, чәбәләнмәс идек,
Ялгызлыкта каласын.

Их, сиздерә сөюләрсез
Бу җиһанның тарлыгы.
Нигә кирәк мәхәббәтсез
Бу яшәүнең барлыгы.

## УРЛАНГАН БӘХЕТ БЕЛӘН

Элегрәк кайда йөрдең,
Очрамадың юлымда?
Кочагымда, әй, иркәләп
Йөртер идем кулымда!

Соңардык шул... Соңарсак та,
Күңел ниләр көтәдер.
Яратсак та гөнаһ кылмый,
Айлар, еллар үтәдер.

Әллә инде тойгыларым
Мәхәббәткә әйләнә?
Якынаям һаман саен,
Чәчләр чәчкә бәйләнә.

Синсез гомер уза диеп,
Сыкранмасын йөрәкләр.
Хыянәтләр кылмый гына,
Өзгәләнсен үзәкләр.

Очрашулар күңелнең бит
Кылларына кагылды.
Хисләребез ташкын булып
Кайларга соң агылды?

Кавыштыр дип теләр идем,
Кабул булса теләкләр.
Бүләк итәр идем сиңа
Беркем бирмәс бүләкләр.

Ә нигә соң бу гомерләр
Сөеп кенә үтмәгән?
Гашыйк токтан кешең белән
Яшәү насыйп итмәгән?

## ИХ, ТАГЫН БЕР ОЧРАШАСЫ ИДЕ

Гашыйк йөрәкләрне кавыштырган
Көз айларын бигрәк юксынам.
Истәлеккә калган шул көннәрдән
Бәхетлерәк чагым юк сыман.

Яшьлегебез хатирәсе булып
Саклanaсың күңелем түрендә.
Сүнмәс йолдыз булып юлларымны
Яктыртасың әле бүген дә.

Өзелеп яратсам да, ни хәл итим,
Гомеремне синсез үткәрәм.
Аерылышу, җирсү-сагышларның
Авырлыгын ялгыз күтәрәм.

Нигә шулай истән чыкмыйсың син?
Төшләремә керәсең елмаеп.
Үткәрәм мин көннәремне шулай
Ялгыз каен кебек моңаеп.

Рәхмәт сиңа, бик азга булса да,
Син бит миңа бәхет китердең.
Мәхәббәтнең излеген тоеп
Яши торган кеше иттердең.

Бер карыйсы иде күзләреңә,
Күңелемә нурын сипкәнче.
Их, тагын бер очрашасы иде...
Якты дөньялардан киткәнче.

## ДИҢГЕЗКӘЕМ, БЕЗНЕ КАРШЫЛА!

Их син, диңгез, кочагыңда синең
Бәхет, шатлык, сагыш биеште!..
Дулкыннарың, таш ярларга бәреп:
— Сөйгән ярың кайда? — диеште.

Әйтмим әле, һаман шулай даулап,
Дулкыннары сорый бирсеннәр.
Диңгез төбендәге серләр кебек,
Нинди серле икән, дисеннәр.

Килеп бастым гүя, даулый торгач,
Иң дәһшәтле дулкын каршына.
Көтеп алган ярым пәйда булды!
Диңгезкәем, безне каршыла!

## ТАМЧЫЛЫ ГӨЛ БУЛЫП АГАМ

Энҗе карлар килеп кунган

Нурлар чәчкән күзеңә.
Күзләреңдә карлар эреп,
Тамып төшә йөзенә.

Синең җылы карашыңнан
Тамчы бөртеге булам.
Тамчы бөртекләре булып,
Керфекләреңә тамам.

Тамчы бөртекләре алар —
Минем күңел яшьләре.
Тамчылардай тама шулай
Сөюемнең хисләре.

Тамчы бөртекләрен, иркәм,
Сыпырма йөзләреңнән.
Тамчылы гөл булып агам
Мин синең күзләреңнән.

## КҮЗ ЯШЬЛӘРЕН КҮРДЕМ ГӨЛЛӘРНЕҢ

Һәрчак туңдым, тәннәремә минем
Гомер буе җылы иңмәде.
Туңу бетте бары сине күргәч,
Тәннәремнән җылы китмәде.

Туңган җаннар тик үзләре белә
Җылылыкның нәрсә икәнен.
Күрмәдең син йөрәк гөлләремнең
Чәчәкләре сулгып кипкәнен.

Сүнәр-сүнмәс янган йолдыз белән
Авыр икән бергә атларга.
Мондый гомер барын белмәгәнмен,
Алып кердең мине утларга!

Гөлләр үскән болыннарны күрми
Гомерләре үтә ирләрнең.
Текәлеп лә миңа карап торган
Күз яшьләрен күрдем гөлләрнең.

## САЙРАП ЯШӘ, СИН БИТ САНДУГАЧ!

Ник моңайдың, сандугачым минем?
Нәрсә булды сиңа, кошчыгым?
Кайгың бармы әллә, әйтче миңа,
Тик моңайма, сайра очынып!

Тирә-юньне һәрчак ямьләндереп,
Сайрап яшә, син бит сандугач!
Сихри бер көч биләп ала җанны,
Моңнарыңны тыңлап юангач.

Һаваларны иңләп оч син, кошчык,
Оч син шулай канат кагынып.
Тыңласыннар синең җырларыңны,
Бар табигать гүя тын калып.

Җыры белән минем йөрәгемә
Гомерлеккә килеп кердеме?
Баш очыннан сайрап бер кош узды,
Ул сандугач түгел идеме?

## ТАГЫН НИЛӘР КҮРЕРМЕН?

Җилләр белән очып китте
Биргән вәгъдәләрең.
Сагышлардан сулыктымы
Бу сылу гәүдәләрең.

Үксеп-үксеп җаным елый,
Елауларын басалмыйм.
Хисләремә ник кагылдың?
Тыныч кына калалмыйм.

Җаннарыма сердәш булып
Сыенмадың, дускаем.
Тагын нилләр күрер икән
Минем газиз башкаем?

## ӘНКӘЙЛӘРНЕҢ ПАР МЕНДӘРЕН...

Күпме буйдак пәһлеваннар,
Исләрең лә китәрлек.
Яр табалмый ялгыз калган
Кызлары да җитәрлек.
Уйланмыйсың яшь чагында,
Маҗаралар эзлисең.
Һавалардан йолдызларны
Берәм-берәм чүплисең.

Белмисең шул гомерләрнең
Бик тиз үтеп китәсен.
Кай арада яшьләреңнең
Кырыкка да җитәсен.

Яшь бара шул, йөзләрдә дә
Кими төшә алсулык.
Чая булып күренсәң дә,
Күзләреңдә моңсулык.

Горур атлап йөрсәң дә син,
Китектер күңелләрең.
Ярларны күп сайлый-сайлый,
Уза бит гомерләрең.

Кайларда соң сез, ялгызлар,
Адашып ла йөрисез?
Каргалган Сак-Соклар кебек
Нигә шулай көйрисез?

Чәчәк аткан чакларыгыз
Үтеп китсен агармый.
Кавышулар ялгызларга
Килсен иде соңармый.

Кияү-киленнәрне көтеп,
Картаймасын аналар.
Әнкәйләрнең пар мендәрен
Саргайтмагыз, балалар.

## КҮПТӘН ӘБИ БУЛЫП БЕТКӘННӘР

Кайтып киләм урман сукмагыннан,
Сулышларым китә киңәеп.
Барган җирдән кинәт тукталдым да
Каеннарга тордым сөялеп.

Җирне кочкан тамырларга шулчак
Ник кагылдым икән баш иеп.
Каеннарның сагыш, моң-зарлары
Җаннарыма китте күк тиеп.

Тирән яткан яшерен серләрне
Саклый белә икән алар да.
Итәгендә иркәләнгән ярлар
Кайда икән хәзер, кайларда?

Күз алдымда кинәт каеннарның
Никтер йөзе шулай үзгәрде.
«Килә алмый озак йөрдең», — диеп,
Кемдер мине гүя тиргәде.

Алар да бит тере җан иясе,
Башларыннанниләр үтмәгән.
Ә шулай да яшел яулыклары
Уңмаган һәм төсе китмәгән.

Үрмәләнеп алар гел биеккә,
Болытнымы әллә тишкәннәр?
Әйтерсең лә, күкнең йөзен айкап,
Җир өстенә килеп төшкәннәр.

Үрмәләнгән чакта, каеннарым,
Калсагыз сез кинәт тукталып,
Керәч-тау да кечерәер төсле,
Торса да ул күккә омтылып.

Ә Керәч-тау, сеңелләрен күзләп,
Биеклектә яшәп калган бит.
Кирәк чакта кочагына алып,

Җил-давылдан саклый алган бит.

Сез исән-сау, күпме гомер узган,
Сөенәмен бергә калганга,
Яшь чагында сездәй бер сылуга
Һуштан язып гашыйк булганга.

Ничәнче кат сезнең яннан үтеп,
Онытылып йөргән чакларым.
Сизмәдем шул сылу каеннарның
Олыгаеп барган чакларын.

Кай арада гыйшык тоткан чагым,
Яшьлек еллар үтеп киткәннәр?
Каеннардай ять-яшь кызлары да
Күптән әби булып беткәннәр.

## ЭХ СИН, КАРТЛЫК...

Егет чакта күп булгандыр
Без кабызган учаклар.
Кызларның да иң чибәрен
Озатып йөргән чаклар.

Хәзер инде картаелды,
Әкрен генә йөримен.
Ул чакларны искә алып,
Кар көртләрен көримен.

Олыгая барсак та шул,
Йөрәк картаймый икән.
Чибәрләргә гел күз төшә,
Мәхәббәт тапмый икән.

Әгәр күрсәң бер чибәрне,
Җитди-җитез атлыйсың.
Таянып ла йөри торган
Таягыңны ташлыйсың.

Кызу-кызу атлаганга
Яхшырамы хәлләрем.
Картлач бу, дип һичкем әйтмәс,
Яңара бит хисләрем.

Миндәй хисле картлачларга
Тик тотмаска кирәкне.
Җитәр инде, вакыт җиткән
Арканларга йөрәкне.

Эх син, картлык, ник йөрисең
Ир-атның башларыннан?
Яшьлек кайтса, алыр идем
Актарып ташларыннан.

## КИЧЕР МИНЕ!

«Кайтар, диеп, яшьлек елларыма!»
Әмер бирсәң иде язмышка.
Гөнаһ кылмый гына яшәр идем,
Үкенмәслек итеп тормышка.

Кичер мине — кинәт тормышыңа
Килеп кергән юньсез бер җанны.
Борчу, хәсрәт, кайгы, сагышлары
Күпме йотты безнең бу канны.

Очрашулар шактый гына булды,
Сизми идем үтеп киткәнен.
Аңлый алмыйм, нигә бу юлы соң
Тирәнгәрәк кереп киткәнмен.

Тирәнгәрәк кереп китүләрдән
Гомер буе куркып яшәдем.
И Ходаем, тәүбәләргә килеп
Гөнаһ кылдым,ниләр эшләдем.

Шуңадырмы, ватык тәгәрмәчтәй,
Читкә тәгәрәде тормышлар.
Их, син, язмыш, белмәдем шул алдан,
Ни күрәсен тагын бу башлар.

Нигә кирәк мондый шаярулар,
Ахырлары булгач аяныч?
Гомер итә-итә аңлыйсың шул —
Янәшәңдә икән таяныч.

Ятлар керсә әгәр тормышыңа,
Ояларын ныклап кормасын.
Гомерлеккә кереп калыйм диеп,
Зур өметләр баглап тормасын.

## БАШЛАРЫҢ ӘЙЛӘНМӘСЕН

Зәңгәр төндә ай яктысы
Иркәләсен йөзеңне.
Болындагы чәчәкләргә
Тиңләдем мин үзеңне.

Өстеңдәге ак күлмәгең
Әй килешә үзеңә.
Очып барган күбәләктәй
Күренәсең күземә.

Сокланып ла карый сиңа
Үз итеп танышларың.
Иркәлидер һәрбер җанны
Сихерле тавышларың.

Ягымлы да, бик моңсу да
Уйчан коңгырт күзләрең.
Иңнәреңнән сарылгандыр
Кара бөдрә чәчләрең.

Матурлыктан, сөюләрдән
Башларың әйләнмәсен.
Сөешсәң дә, каушалмыйча
Чәчләрең бәйләнмәсен.

## ЕЛМАЕП ТӨШЕМӘ КЕРСӘ ДӘ

Кайда сез, узылган гомернең
Тынгысыз, шау-шулы еллары?
Һичкайчан, юк, чыкмас исемнән
Тормышның бормалы юллары.

Әйтегез, мөмкинме оныту
Яшьлекнең кояшлы көннәрен?
Хәтердә йолдызлы кичләрдә
Мәхәббәт утында дөрләвем.

Хәзер дә хисләрем яктыра,
Сөйгәнем төшемә керсә дә.
Яшьлекне булмый шул кайтарып,
Үзе гел янәшә йөрсә дә.

## ЭХ, БЕР УРАП ГОМЕР ЮЛЛАРЫН...

Исеңдәме кышкы иртәләрдә
Икәү бергә атлар җиккәннәр,
Толыпларга төренеп, икәүләп
Ерак юлга чыгып киткәннәр?

Урман юлларыннан барган чакта
Шыгырдатып ап-ак карларны,
Кайтып килә идек туган якка,
Көнләштереп бездәй парларны.

Еллар узган саен уйландыра
Гомерләрнең бик тиз агышы.
Бер кайтаваз булып ишетелә
Шыгырдаулы чана тавышы.

Кышның салкын, аяз көннәрендә,
Эх, бер урап гомер юлларын,
Бер йөрисе иде чаналарда,
Кайтарып ла яшьлек елларын.

## ЯШЬЛЕГЕБЕЗ ӘРӘМ ҮТМӘДЕ

Лапас өсләреннән чыккан айның
Яктысыннан хисләр яңара.

Төнге авыл йоклый, әмма ләкин
Яшьлек белән сөю шаяра.

Озак йөрдек айлы матур төндә,
Нурларына күмелеп икәүдән.
Курка идек ямьсез уйлардан без,
Төн тынлыгын бозып китүдән.

Яшәп туймас кебек ул вакытлар,
Шатлыклардан күңел тулгандыр.
Иң саф моңы минем йөрәгемнең
Шул чакларда, бәлки, тугандыр.

Таң чыкларын кулларыма алып,
Чәчләреңә килә сибәсем.
Ай нурыдай сарылып иңнәреңә,
Килде минем кочып үбәсем.

Еллар узсалар да, йөрәкләрдән
Тәүге сөйгән ярлар китмәде.
Сылукайлар һаман күз алдымда,
Яшьлегебез әрәм үтмәде.

## УЛ ЧАКЛАР...

Кичке авыл, кызлы өйләрдә
Яшь-җилкенчәк йөри уралып.
Әйтерсең лә зур бер кояшны
Атлас чаршау алган уратып.

Төн шәүләсен ярып, каяндыр
Ай да калкып чыккан адашып.
Айның нуры төшкән сукмактан
Бәхетлеләр атлый парлашып.

Тальян урый яшел болынны,
Моңнар сеңеп кала гөлләргә.
Канатланып әкият кошыдай,
Күңел белми нәрсә эшләргә.

Хисләр ташкынына бирелеп,
Чүт егылмый «калдык-абындык»,
Оялып ла айның нурыннан
Кинәт кенә читкә тайпылдык.

Чык суларын алып үзенә,
Бер кайгысыз үсә үләннәр.
Эндәшкәндәй була үзләре:
«Бик бәхетле парлар икәннәр».

Икәү генә алар дөньяда!
Җилләр, сез дә юлга чыкмагыз.
Сез, үләннәр, син дә, әй, болын,
Тыңламагыз серне, йоклагыз!

Тимик әйдә, сергә туйсыннар,
Нәрсә икән алар уенда?
Күрмәмешкә салыш син дә, тау!
Серләшсеннәр синең куенда.

Таң атканын сизеп, мөгаен,
Баш калкытып килә гөлләрем.
Төн югала, төннәр узса да,
Сүрелмәгән кайнар хисләрем.

Ул чакта мәхәббәт тә гамьсез
Уйлардан тыелып калган бит.
Кирәксә, йөрәкләр яшьлекнең
Ярсуын йөгәнли алган бит.

## ИКЕ ИГЕЗӘК ЕГЕТ ГАРМУН ТАРТЫП...

Бик яшь идек әле ул чакта без,
Хыяллар да дәртле булганмы?
Ике игезәк егет гармун тартып
Иңли идек төнге урамны.

Озын көннәр буе көтү көтеп,
Белмәгәнбез ару-талуны.
Төн пәрдәсен ертып, тальян моңы
Күмә иде бөтен авылны.

Тыкрыкларны урап чыкканнан соң
Тынып кала иде соң гына.
Кемнәр уралмаган таң алдыннан
Яңгыраган гармун моңына?

Йокылары качкан кызларның ул
Күңелләрен үзенә чакыра.
Тәрәзәләр аша карый алар,
Пәрдәләрен ачып чак кына.

Бөтен җиһан гүя гашыйк була
Җанны җилкендергән көйләргә.
Керәч-тауларының кайтавазы
Килеп керә тып-тын өйләргә.

Әй ул еллар! Гүзәлләрне уйлап,
Сиздермичә эчтән янулар.
Гармун уйнап, шашып җырлый-җырлый,
Никрутларны озатып калулар.

Хушлашырга килгән туганнарын
Юатулар, алып кочакка.
Яшьлек шулай бер дә узмас кебек
Тоела иде безгә ул чакта.

Чиккән яулык, вәгъдә бирүләргә
Шаһит булып калды гармуннар.
Үзебезнең дә баштан үтте инде

Аерылулар, сагыш, зар-моңнар.

Кайчандыр бит без дә бик яшь идек,
Җилеп үтә идек юллардан.
...Ике игезәк егет гүя әле дә
Гармун тартып уза урамнан.

## ЯҢА ЯУГАН КАР ӨСТЕНДӘ

Керәч-тауларның түбәсен
Ап-ак карлар каплаган.
Шунда яңа эзләр салып,
Кемдер үргә атлаган.

Аны озатып  калганнар
Тын инеш тирәкләре.
Тылсымлы соң туган якның
Кышкы саф бизәкләре.

Җем-җем иткән сыкылары
Күз керфекләрен сара.
Таңда яуган ап-ак карлар
Гомергә истә кала.

Олыгая баруларын
Искәртәләр яшьләргә.
Аннан көмеш кырау булып
Күчә алар чәчләргә.

Тик күңел картаймый һаман,
Узасы юллар ерак.
Их, бер йөреп кайтсаң иде,
Бөтен дөньясын урап!

Ник биек-биек тауларга
Менмәскә әле тагын?
Ник онытырга йөрәкнең
Куркусыз чая чагын?

Юк, бер җирдә дә калмабыз
Югалып һәм адашып.
Ап-ак карлар яуган тауда
Йөрик әле парлашып.

## ПАР БУЛСЫН КАНАТЛАР

Күңелем ашкына
Кайларга, кайларга?
Йөрәгем җилкенә
Бирелмәс уйларга.

Җилләрдә тибрәлеп
Утыра гөлләрем.

Каядыр еракка
Текәлгән күзләрем.

Керәмен кичләрен
Ялгызым өйләргә.
Юксыну хисләрен
Кемгә соң сөйләргә?

Эндәшә хисләрем
Түземле булырга.
Яшәгән гомердә
Кешедәй калырга.

Ташландык өйләрнең
Бер ямен сизмимен.
Ялгызлык газабын
Тоеплар яшимен.

Ихтыяр көчләрен
Кайлардан алыйм мин?
Бары тик Ходайдан
Сабырлык сорыйм мин.

Тормышның юлларын
Бәхетле узарга
Пар булсын канатлар,
Бирешмик моң-зарга.

## СӨЕП ТУЙМАС ЯРЫМ БУЛ

Күпме эзләп йөрдем сине,
Очрамадың юлымда.
Күкләргә багып уйландым
Гел-гел синең турында.

Йолдызлар да миңа таба
Карап тора иделәр.
Ап-ак сирень чәчәкләре,
Пар килгәнсез, диделәр.

Яшермичә каеннарга
Сөйләдем серләремне.
Алар тапшырсыннар сиңа
Әйтәсе сүзләремне.

Алгы көндә юлларымны
Яктыртучы нурым бул.
Тормышымда гомер буе
Сөеп туймас җырым бул.

## ҮКЕНЕРЛЕК БУЛМАСЫН

Көнгә түгел, гомерлеккә
Ярны сайларга кирәк;

Ашыкмыйча, барлык яктан
Төптән уйларга кирәк.

Урамнардан узган чакта
Карап калырлык булсын.
Буйдаклар да көнләшерлек,
Сабак алырлык булсын.

Көянтәле чиләкләрең
Биеп торсын кулыңда,
Су алганда, сандугачлар
Сайрап торсын юлыңда.

Яратканда, ятлар белән
Хисләреңне бүлешмә.
Ятлар белән көрәшә бел,
Көрәшкәндә бирешмә.

Булыр-булмас ярлар белән
Гомерләрең узмасын.
Яр булырлык ярлар сайла,
Үкенерлек булмасын.

## ГОМЕРЛЕК ЯР БУЛЫРМЫН

Чәчәкләрне ерып килә,
Тик берсен дә өзмидер.
Төпләренә иелеп карый, —
Аннан ниләр эзлидер.

Сорадым мин чәчәкләрдән
Сөйгәнемнең уйларын.
Кавышырга ризалашып,
Кайчан бирер кулларын?

Күпме көтсәм дә, мин, дустым,
Синең белән калырмын.
Сөеп-сөелеп яшәр өчен
Гомерлек яр булырмын!

## СУЫРЫП АЛАСЫ ИДЕ

Моңсу гына уйландыра
Эчкерсез карашларың.
Боз йөрәкне эретердәй
Ягымлы тавышларың.

Иң өсләрең буйлап киткән
Кара бөдрә чәчләрең.
Әллә инде сихерләде
Уйчан зәңгәр күзләрең?!

Син булмаган чакларымда
Күңел тула сагышка.

Моңланадыр йөрәккәем
Кош сайраган тавышка.

Шаулап аккан гомер белән
Бергә каласы иде.
Йөрәкләрдән әрем тәмен
Суырып аласы иде.

## КЫРЫСЛАНА МӘЛЛӘ КҮҢЕЛЕМ

Авыр сүзләр әйтеп, кайчагында
Рәнҗетәмдер синең җаныңны.
Болай да бит инде иңнәреңнән
Аз какмаган җиле-давылы.

Ни булды соң миңа, югыйсә бит
Таш бәгырьле кеше түгелмен.
Замананың кырыслыгын күреп
Кырыслана мәллә күңелем?

Усалланып түгел, сөеп-сөелеп
Гомер итик әле җирдә без.
Бу дөньяга без бит бер-беребезне
Назлап яшәр өчен килгәнбез.

## ҮПКӘЛӘМӘ МИҢА

Шулай дисәм дә бит, үпкәләргә
Хаклыгыңны беләм мин бүген.
Тик һаман да бергә минутларны
Ядкарь итеп саклый күңелем.

Синең кебек мин дә ничә еллар
Эчкә йотып йөрдем кайгымны.
Мәрхәмәтсез язмыш көтмәгәндә
Аерды шул безне, аерды.

Нинди матур дөрләп киткән иде
Икәүләшеп яккан учаклар.
Хәзер күпме генә сыкрансаң да,
Кире кайтмас инде ул чаклар.

Нишләсәк тә, бергә булалмабыз,
Сулар акмый, диләр, үрләргә.
Ә шулай да яшьлек хисләренең
Исәбе юк пыскып сүнәргә.

Үткәннәрне сагынып искә алам
Һәр адымда, һәрбер сулышта.
Тәүге мәхәббәтнең кайнарлыгын
Тоеп яшик әле тормышта.

## БЕРНИ ТҮГЕЛ БЕЗГӘ

Берни түгел безгә чиксез дәрья,
Юкка гына дулый, ярсына.
Чал диңгезләр аша кавышырбыз,
Син дә йөзеп килсәң каршыма.

Берни түгел безгә, киң галәмгә
Алып очсалар да кораблар.
Җирдә һаман бергә булачакбыз,
Каерылмасын гына канатлар.

Берни түгел безгә җил-давыллар,
Бозлы таулар, утлы өермә.
Баш имәбез, әгәр бер-беребезгә
Тугрылыклы булсак гомергә.

Берни түгел безгә зилзиләләр,
Тетрәтсә дә бөтен җиһанны.
Уртак сөю белән ялкынланган
Йөрәкләрне җиңәр көч бармы?!

## КАЛ МИНЕМ ЯННАРЫМДА

Урманнарга ялгыз керсәм,
Эзләп табарсың микән?
Сайлап алып, күкрәгемә
Гөлләр кадарсың микән?

Янарсың микән күгемдә,
Сүнмәс йолдызлар булып.
Кайгыларга юлыкканда
Алырсың микән йолып.

Юлдашым, юатучым бул
Борчулы таңнарымда.
Кайда гомер кичерсәм  дә,
Кал минем яннарымда.

## ЕЛМАЙ ӘЛЕ

Керфекләрең тагын юешләнгән,
Ничек кенә сине юатыйм?
Авыр сүзләремне онытырлык
Нинди генә җылы сүз катыйм?

Үпкә катыш салкын карашларың
Минем йөрәкне дә телә бит.
Исеңдә тот: безнең сөенечләр дә,
Кайгылар да әле бергә бит.

Тик син генә минем мәхәббәтем,
Борчуларым, олы шатлыгым.
Син китерден миңа тормыш ямен,
Язлар алып килдең, матурым.

Синең күз яшеңне беркайчан да
Килми минем, килми күрәсем.
Елмай гына, бары елмай гына,
Елама син, яме, гүзәлем.

## КАНАТЛАРЫМ БУЛСА ИҢНӘРЕМДӘ

Торган җиргә күңел күнексә дә,
Ялгызлыкка булмый күнегеп.
Җирсәүләрем шуңа көчәядер,
Сөю хисе белән үрелеп.

Кайчан безгә татлы кавышулар
Насыйп булыр икән тагын да?
Канатларым булса иңнәремдә,
Очып барыр идем яныңа.

Яшерми әйт, дустым, син дә шулай
Зарыктыңмы мине күрергә?
Аерым яшәүләре җиңел түгел,
Бергә булсак иде гомергә!

## САГЫНАМ СИНЕ

*Тормыш юлдашым Лилиягә*

Көннәр-төннәр һаман уза тора,
Күктә — кояш, җирдә мин янам.
Җирнең җылылыгын тоймас идем,
Ут алмасам синең дөньяңнан.

Торып басам кояш чыгышларын,
Кояш баешларын карарга.
Ярый әле язмыш насыйп иткән
Бер-беребезгә сөеп карарга.

Таулар түбәсендә кичке шәфәкъ
Алмаларга охшап кызара.
Шәфәкъларга күмелеп тып-тын гына,
Серләшәсе иде үзара.

Чишәр идем күпме заманнардан
Җыелып килгән йөрәк серләрен.
Гомерем буе тугры синең кебек
Ышанычлы дусны күрмәдем.

Сагындырган көннәр күбрәк микән,
Сагынасы көннәр күбрәкме?
Сагынмаска түгел, сагынганда
Сабырлыкка күндер йөрәкне.

## ТОРМЫШЫМНЫҢ БЕТМӘС НАЗЫДЫР

*Тормыш юлдашым Лилиягә*

Күзең нинди — холкың шундый, диләр,
Бу сүзләрдә хаклык бармы соң?
Күзгә карап белеп булса икән,
Әй, чыннан да кеше язмышын.

Соргылт күзләреңне текәп миңа,
Чумдың тагын нинди уйларга?..
Синекедәй соргылт күзләргә соң
Мөмкинмени сөеп туярга?!

Синең күзләрдәге җылылыкны
Ала алмас йөрәк беркемнән.
Синең күзләр минем күңелемә
Күпме яшәү көче бөркегән?!

Кара күзләр — тәүге мәхәббәттер,
Зәңгәр күзләр — яшьлек языдыр.
Синең соргылт күзләр тормышымның
Гомер буе бетмәс назыдыр.

## КҮЗЛӘРЕМНЕ АЛМЫЙ ТӘРӘЗӘДӘН

Күзләремне алмый тәрәзәдән
Көтеп алам синең кайтканны.
Нинди бәхет шулай бергәләшеп
Күзәтүе таңнар атканны.

Әй бу гомер нигә тиз үтә соң,
Булмый аны, булмый туктатып.
Күптәнмени әле яшьлек белән
Калган кебек идек хушлашып.

Ә ул бездән һаман аерылмаган,
Әзер торган кабат кочарга.
Кем теләми хыял канатында
Офыкларны иңләп очарга.

Беребез дә фәрештәләр түгел,
Баштан төрле хәлләр узгандыр.
Ара-тирә нәфес дигәне дә
Бәйдән ычкынгалап куйгандыр.

Ярый әле шулчак көтмәгәндә
Син очрадың барыр юлымда.
Яшьлегемә насыйп мәхәббәтем
Булган икән синең кулыңда.

Юл буенда гөлләр әйтерсең лә
Безне котлап пардан киенгән.
Һәр адымда синең янәшәңдә
Атлап баруыма сөенәм.

Бүген дә бит, тәрәзәмне ачып,
Көтеп торам синең кайтканны.
Нинди бәхет шулай икәү бергә

Каршылавы таңнар атканны.

## КҮҢЕЛЕҢӘ ЯЗЛАР КИТЕРЕРМЕН

Кояш баеп барган минутларда,
Бик ямансу була кичләрен.
Андый чакта сине юатырга
Матур, җылы сүзләр эзлимен.

Ачы язмыш авыр, үтәлмәслек
Киртә корса барыр юлыңа,
Кайгы-бәлаләрдән саклар өчен,
Мин килермен синең янына.

Моңсуланма, күреп бакчаларда
Гөлләреңнең иртә сулуын.
Күңелеңә язлар китерерлек
Сөйгән кешең үзем булырмын.

Күңелеңдәге изге хисләреңә
Гомерем буе тугры калырмын.
Тоеп яшә талмас иңнәреңә
Таянырлык дустың барлыгын.

## ИСКӘ ТӨШЕРМӘ

Җиңел түгел кылган гамәлләрне
Искә төшерүләр азактан.
Ничек кенә коткарыйм соң сине
Бәгыреңне телгән газаптан.

Керфегеңә тамган күз яшеңне
Килми минем, килми күрәсем.
Син бит минем күңелемә бары
Елмаюың белән кергәнсең.

Күзләрең тик тагын юешләнгән,
Тынгылыгын җуйган йөрәгең.
Белмим бүген сине юатырга
Нинди назлы сүзләр кирәген.

Нинди сагыш иңгән йөзләреңә,
Ник борчулы синең уйларың?
Мин бит әле җирдә син үстергән
Гөлләрне дә сөеп туймадым.

Килә минем сине барлык-барлык
Афәт-кайгылардан саклыйсым,
Тормыш юлларында гомер буе
Синең белән бергә атлыйсым.

## КҮҢЕЛЕМ СИНДӘ МИНЕМ

Күңелем һаман синдә, синдә минем,
Синдә минем барлык уйларым.
Иң-иң олы бәхет түгелмени
Тоеп яшәү җирдә син барын.

Канатланып йөрим юлларымда,
Кайгым булса, ул да онытыла.
Кайда гына булмыйм, уй-хисләрем
Син яшәгән якка омтыла.

Тик син генә минем куанычым,
Юанычым, өметем син генә.
...Менә тагын дөнья гаме баскан
Башкаемны салам иңеңә.

## ИҢ ЗУР БӘХЕТ ИТЕП

Ничә еллар инде синең белән
Бергә-бергә гомер кичердек.
Төнге йокыларың йокламыйча
Көтеп алдың, кайтсам кичегеп.

Һәм беренче юатучым булдың
Кайгыларга тарыган чагымда.
Хәзер дә бит ялгыз көннәреңдә
Шик-шөбһәләр үрли җаныңа.

Беләм, иркәм, андый минутларда
Төрле уйлар килә башыңа.
Ә үземне күргәч, айдай балкып,
Йөгереп чыгасың син каршыма.

Матур төш күргәндәй онытылып
Калам шунда синең иркеңдә.
Сулышыңнан, якты карашыңнан
Гаилә җылылыгы бөркелә.

Иңнәреңә сарылам, иң-иң кыен
Сорауларга җавап тапмасам.
Кем гаепләр, күкрәгемә кысып,
Фәрештәм, дип, сине атасам.

Ә бит әле безнең бу тормышта
Очрап куя шундый абзыйлар:
Мәхәббәткә алар күңел ачу,
Уен гына итеп карыйлар.

Сабыйлары ятим үсүне дә
Бернигә дә алар санамый.
Уйламыйча кылган гамәлләре
Күпме йөрәкләрне яралый?

Гомер иткән чакта кем теләмәс
Бөтенлеген торган йортының?
Сүнүенә, шөкер, юл куймадык

Икебез яккан учак утының.

Тормыш агышында капкабызны
Нинди генә җилләр какмады!
Гайбәт-йолалардан безне һәрчак
Синең сабырлыгың саклады.

Бергә яшәү безгә Тәңребездән
Иң зур бәхет итеп бирелгән.
Сорыйм синнән: гомерем ахырынача
Кулларыңны алма иңемнән.

## СИНЕҢ БЕЛӘН БЕРГӘ АТЛЫЙСЫ

Күпме әйтәм, искә төшермә, дим,
Ялгышуым әйтмә азактан.
Ничек кенә сине йолып алыйм
Җаның телгәләгән газаптан?

Синең күз яшеңне беркайчан да
Килми минем, килми күрәсем.
Елмай гына, бары елмай гына,
Тик елама, яме, гүзәлем.

Керфекләрең тагын юешләнгән,
Ничек кенә сине юатыйм?
Авыр бәрелүемне оныттырлык
Нинди генә җылы сүз катыйм?

Үпкә катыш салкын карашларың
Минем йөрәкне дә теләбит.
Бүлгәләмә, безнең сөенечләр дә,
Кайгылар да әле бергә бит.

Тик син генә минем мәхәббәтем,
Борчуларым, олы шатлыгым.
Син китердең миңа тормыш ямен,
Язлар алып килдең, матурым.

Елмаюлы карашларың белән
Бар кайгымны йолып алсаңчы.
Безгә әле кырыс еллар аша
Синең белән бергә атлыйсы.

## ИСӘН ЧАКТА ҺӘЙКӘЛ КУЯРЛЫК

Туры килде яшьлек елларында
Күпме кызлар сөеп кочарга.
Хыялланып, сөю  канатында
Һаваларны иңләп очарга.

Без фәрештә түгел, бәлки, шуңа
Безнең гөнаһлар күп булгандыр.
Шәраб эчеп, акыллардан язып,

Уйламыйча гамәл кылгандыр.

Яшь барса да, йөрәк картаймый шул,
Чибәрләргә күзләр төшкәли.
Их, ул шайтан әллә гел янәшә, —
Күңелләрне ничек өткәли.

Тәүбә иттем башка алданмаска,
Алдамаска сөйгән ярларны.
Алданганнар кичерсеннәр иде,
Искә алып бергә чакларны.

Түземле дә, акыллы да булдың,
Үзең белән туган сабырлык.
Синдәй гүзәл, тыйнак затларга
Исән чакта һәйкәл салырлык!

**ЭЧТӘЛЕК**

Күктә очмый егет, җирдән атлый *(Нурисә Габдуллина)*

**Уянырга кирәк, халкым!**

Тугайлардан күзем алалмыйм
Аермасын туган авылдан!
Зәңгәр күлем
Чулман буйларында уйлану
Күңелләргә якты нур тулсын
Горурланып яшим синең белән
Китә алмам кебек
Килдем сиңа
Туган авылым
Их син, дөнья!..
Дуслар гафу итсен
Килмәсмени йөзеп китәсем?!
Яратам мин
Кышлары бит язлар булалмый
Гомеремнең тагын бер көне
Туган туфрак
Кырларыңда туган моңнарың
Дулкынлансын кырлар!
Тагын язлар килде
Туган якның якты язына
Керәч-тау
Яратам мин сине, алтын көз
Онытмаган туган авылым
Бабамнар килгән ерактан
Ерак бабамнарның моң-зары
Малай чагым җырын ишетәм
Кодрәтеңнән килсә
Кичерә алсаң иде, нигез-йорт!
Башка җирдә түгел
Өй каршында үскән чыршылар
Ә нигә соң әле...
Гомеркәйләр әрәм узмасын
Авылдан аерылгач
Мине, зинһар, күктән эзләмәгез
Туган якның сихри көче
Ялгыз нарат хатирәсе
Игенче син...
Кала кешеләре сыйлансын
Әй ул еллар, үткән гомерләр
Ипекәйне һәрчак кадерлик
Вакытлыча була күрмәсен
Искә алып малай чакларны
Чөгендерләр гөрләп утыра
Их, дускаем, ялгышма
Авыр уйлар күбрәк керәдер
Һай, бу картлык хәлләре
Ник ишмәдем икән ташларымны?!
Капламасын каралык
Авыл эчеп юана
Чаң сугарга вакыттыр
Сагынырсыз авылларны
Галәмгә чаң кагасы!
Шәрә йөрерләргә калмасак...
Яшибез җайлап кына
Менә шундый заман җитәр
Октябрь бәйрәмендә
Әй бу базар хәлләре
И туган җирем...
Якты көннәреңә җитәрсең
Нәрсә булды сиңа, Русия?..
Кем соң тиеш?
Заманалар бигрәк авыр, диеп...
Йомышың төшә калса...
Өмет белән яшик

Хафаланмыйк әле
Һаман юлда
Балкысаңчы Рәсәй күгендә
Уяныргa кирәк, халкым!
Артыгын көчәнмәгез
Еракларга торыр күренеп
Сабырлыклар сорыйк Ходайдан
Олуг бәйрәм Рамазан
Татар исемен горур йөртергә
Мәңге яшь син
Әүлия җан тагын туармы?
Туфраккаен килә үбәсем
Салынгансың изге нигезгә
Яктыртучы йолдыз син
Үз кыйблаңны саклап калгансың

**Әнкәйләргә булган мәхәббәт**

Әнкәйләргә булган мәхәббәт
Сары яфрак җыйдым, әнкәем!
Рәнҗетмик изге җаннарны
Рәхмәт сиңа барысы өчен
Юк, үкенмәс идем
Каплый кебек әнкәй куллары
Ешрак кайтыйк
Бер сылуы итеп
Күз алдыма килеп басасың
Әнкәмнең күзләрендә
Кадерен белик аналарның
Һай, гомер итүләре
Сугыш булмас иде дөньяда
Игезәкләрең сине ташламас
Олы җанлы матур кеше
Кошларда да бала хәсрәте
Ак теләкләр теләп
Син бит җирнең иң зур шатлыгы
Якты өмет булып балкыдың
Кадерләрен белик
Әткәйгә
Ярый әле әткәй булган
Тимә, картлык, безнең нигезгә
Мин бит әле ятим түгелмен
Уңдым, диеп, сездән, улларым
Карауучысыз калган балалар

**Кичерегез безне, гүзәл затлар**

Тынма, күңел
Кояш булып балкы
Күңелләргә язлар китерә
Адаштырмас мине юлларым
Көзге уйлану
Әллә нишләдем
Сине юатырдай сүзләр эзлим
Бергә булмасак та
Сер сынатмас гүзәл затларга
Гомерлеккә шулай калыгыз
Киек Каз Юлы буйлап
Тол хатынга
Парсызларның хәлен кем аңлар...
Бик күп алар
Кадерләрен белик аларның
Толымнарга тимәгез!
Шул ук толымнар!
Чибәрләргә гашыйк булдым, диеп...
Кошлар телен белмәсәм дә
Калдыр мине тынычлыкта
Алданмасын, дуслар, күңелегез
Акылларыңны җуйма
Әле хәзер генә аңладым
Кичерә һәм сөя белсеннәр

Хисләреңне йөгәнлә
Тыйнаксызлык һич  килешми
Белми алар...
Нишлим соң, дуслар?
Синең эзләреңнән
Сагынырсың кебек
Көт син, иркәм
Түзә алыр микән?
Юлың үтсә киң елгалар аша
Бәхетле булалмассың!
Сөйгән ярың ташлагач
Бер күрешү өчен булса да
Сине көтеп
Соңарган мәхәббәт
Синең язларыңа сусадым
Ник очрадың минем юлымда?
Мәхәббәтсез мөмкин түгел
Урланган бәхет белән
Их, тагын бер очрашасы иде
Диңгезкәем, безне каршыла!
Тамчылы гөл булып агам
Күз яшьләрен күрдем гөлләрнең
Сайрап яшә, син бит сандугач!
Тагын ниләр күрермен?
Әнкәйләрнең пар мендәрен...
Күптән әби булып беткәннәр
Эх син, картлык...
Кичер мине!
Башларың әйләнмәсен
Елмаеп төшемә керсә дә
Эх, бер урап гомер юлларын...
Яшьлегебез әрәм үтмәде
Ул чаклар...
Ике игезәк егет гармун тартып...
Яңа яуган кар өстендә
Пар булсын канатлар
Сөеп туймас ярым бул
Үкенерлек булмасын
Гомерлек яр булырмын
Суырып аласы иде
Кырыслана мәллә күңелем
Үпкәләмә миңа
Берни түгел безгә
Кал минем яннарымда
Елмай әле
Канатларым булса иңнәремдә
Сагынам сине
Тормышымның бетмәс назыдыр
Күзләремне алмый тәрәзәдән
Күңелеңә язлар китерермен
Искә төшермә
Күңелем синдә минем
Иң зур бәхет итеп
Синең белән бергә атлыйсы
Исән чакта һәйкәл куярлык

Заказное издание

*Хусаен* ***Ягъфар***

(**Ягъфаров** Хусаен Гумерович)

**ПРОЩАЙТЕ И ЛЮБИТЕ**

*Стихи*

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Заказ басма

*Хөсәен* ***Җәгъфәр***

(**Җәгъфәров** Хөсәен Гомәр улы)

**КИЧЕРӘ ҺӘМ СӨЯ БЕЛСЕННӘР**

*Шигырьләр*

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм
компьютерда биткә салучысы *Т.В.Гредюшко*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2006. Форматы 70×100 $^1/_{32}$.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,40 + фор. 0,16.
Шартлы буяу-оттиск 10,9. Нәшер-хисап табагы 8,49 + фор. 0,28.
Тиражы 1000 д. Заказ З-1190.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.